Фәрит Суфияров

# Йолдызлар җиле





Фәрит Суфияр улы Суфияров Яңавыл районының Исәнбай авылында туып үскән. Ул урта мәктәпне тәмамлагач, Уфа финанс техникумында белем ала.Төрле оешмаларда финансист-экономист булып эшли. Педогогия институтын тәмамлап, район газетасында әдәби хезмәткәр, мәктәптә директор вазифаларын башкара.

Башкортстанның төньяк-көнбатышындагы яшь һәм башлап язучыларны туплаган «Замандаш» әдәби берләшмәсенең җитәкчесе була. Хәзерге көндә Яңавыл язучылар оешмасының җаваплы секретаре булып эшли.

Шигырьләре вакытлы матбугатта, коллектив җыентыкларда дөнья күрә.Дистәдән артык китап авторы. Радио-телевидениедә аның күп кенә җырларын популяр җырчылар башкара. Башкорт әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүче хезмәтләре өчен шагыйрь Фәрит Суфияровка

«Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә. Ул Гали Чокрый,Фатыйх Кәрим исемендәге премия лауреаты булды.

Фәрит Суфияров

# Йолдызлар җиле

Шигырьләр һәм поэма

Уфа-2006
“Слово” нэшрияте

УДК 821.512.145-1
ББК 84-5(2Рос.Тат)
С909

**Фәрит Суфияров**
Җыентыкка шагыйрьнең соңгы елларда язылган лирик-фәлсәфи шигырьләре тупланган. Заманыбызның проблемалары борчый аны, шул кыенлыклар алдында сыгылып төшмәскә чакыра ул безне.

ISBN 5-87308-339-8

©"Слово" нәшрияте
©Фәрит Суфияров

# Дөнья ямен җибәрмик

Бездән дөнья ямьле калсын әле,
Йортлар төзик,иген үстерик.
Килер буын яшьләр рәнҗемәсен,
Тормыш күркәм, хәстәрен күрик.

Җир-анабыз җәннәт бакчасы күк,
Асыл гөлләр белән бизәлсен.
Кылган эшләребез күренеп торсын,
Ай-йолдызлар күктән күзләсен.

Кәүсәр чишмәләрнең күзен ачыйк,
Дәва тапсын сусаган җаннар.
Исән чакта сүнмәс хезмәт дәрте,
Куәтләнеп йөрәкләр янар.

Без яшәгән еллар шаһит булып,
Басар бер чак тарих каршына.
Гадел хөкем чыгар, бәһаланыр,
Җавап тотарбыз ич барсына.

Корал тотып яу кырына чыкмыйм,
Сәлам бирәм кереп күршемә.
Илем имен - тынычлыгың кирәк,
Хезмәт сөйгән барлык кешегә.

*   *   *

# Кешеләргә булсын кирәгем

Борчуларым бетеп торганы юк,
Олы өмет белән яшимен.
Ходай белер әгәр гонаһ кылсам,
Кешеләрдән һичтә яшермим.

Урлашмадым, кеше таламадым,
Тапканнарым хезмәт җимешем.
Шаһит булсын кулга йөкләп алган,
Илгә багышланган бар эшем.

Тәүбә итәм кыңгыр эштән куркам,
Мин йөземә кара якмадым.
Кимсетелә кеше, хаксызлыктан,
Авыр хәлгә тарыгач якладым.

Изге теләктәмен, дога кылам,
Җиргә орыла башым, маңгаем.
Битарафлык инде күрсәт дисәм,
Каһәр укыр халкым мөгаен.

Намусымны саклыйм тап төшерми,
Хезмәт бары яшәү терәгем.
Мин башымны горур йөретермен,
Кешеләргә булса кирәгем.

* * *

# Кояшым, аем да бул

Җан өшегән, калтыраган чакта,
Җылы тапмый иза чигәмен.
Бик кызганыч үз-үземне кочам,
Кечерәеп калам, чүгәмен.

Каным туңа, йөрәк хәлсезләнә,
Авыр сулап куям бу мәлне.
Давыл кубар, җир тетрәр бәлки,
Ничек тә кил, бел син хәлемне.

Син кил миңа якты кояш булып,
Күңел бозларымны эретерсең.
Хисләремне уят ташкын итеп,
Көткән язларымны китер син.

Мөләемле карашыңны күрсәм,
Бөркет сыман канат кагармын.
Тормыш учагына ут алырмын,
Җан җылысы шунда табармын.

Кояшым бул инде, аем бул син,
Энҗе нурлар чәчеп китәрсең.
Моңсу минутымда рухым төшсә,
Йолдызларга кадәр күтәр син.

* * *

# Туган җирдә мәхәббәтем

Авылымнан китәм дигән чагым,
Бураннарда, кара күзләрдә.
Сандугачлы язлар, җәйләр җитсә,
Уйлар башка тагын үзгәрә.

Бер фикергә һаман киләлмимен,
Хушлашырга булмас быелда.
Нигез ташын, туган туфрагымны,
Ташлап китүләре кыенла.

Көмеш кыңгыраулы чишмәләрем,
Дулкын шаулый зәңгәр күлемдә.
Мәхәббәтем, шатлыкларым барда,
Күтәреләм бәхет күгенә.

Якты таңнар тәрәзәмдә балкый,
Алмаларым алсу аллана.
Туфрак җылың каннарыма күчә,
Алмаштырмыйм аны калага.

Ата-бабам нигез корган кебек,
Чәчкән-урган, иген үстергән.
Куанычлар табышлары белән,
Хезмәт сөйгән, гомер кичергән.

Үз җиремә шөкер итеп яшим,
Мәхәббәтем арта, куанам.
Иген үсә, гөлләр чәчкә ата,
Барда уңа минем кулымнан.

# Шатлыкларым уртак булсын

Гомер сукмаклары
Тасма юллар түгел,
Тыныч кына беләм узмасын.
Мәхәббәтем көчле көнләшәсең,
Шатлыгыма кулың сузасың.

Үткәнемнән кайтам бүгенгегә,
Җавап тотам миннән сорала.
Тормышта бит кеше бик күп тапкыр
Акыл көче белән сынала.

Сүз ярасы,күңел җәрәхәте,
Бозлар булып кала, эреми.
Көткән ышанычым кысыр булса,
Офыкларда язлар күренми.

Чигәләрем кыса, каным кыза,
Кеше бәхетенә көнләшмим.
Өлешемә чыккан шатлыкларны
Дусларыма барып өләшәм.

* * *

# Кулларымны канат итәм

Ике кулны ике канат итеп,
Урап чыгам галәм киңлеген.
Киңлекләрне тирәнлеге белән,
Сыйдырала үзенә күңелем.

Абагалы яшел урман буе,
Зәңгәр рәшәләр тирбәлә.
Диңгез генә бердә күрсәтми
Җәүһәрләрен саклый тирәндә.

Йолдызларга карап күзем кыза,
Баш өстендә балкып күренә.
Күкләремдә оча корабльләр,
Биеклеккә һаман үрелә.

Галәм киңлекләрен айкап әллә,
Хезмәт вахтасыннан кайтасың.
Гаҗәпләнмим һичтә сюрпризга,
Алып төшсәң зәңгәр ай ташын.

Уйлар йөгерә чиксез киңлекләргә,
Мәртәбәле беләм данлыйсың.
Каһарманнар узган юлны сайлап
Килә минем бәхет даулыйсым.

* * *

# Офыкларга төште кояш

Галәм түреннән үк кояш төшеп,
Офык читләрендә күз кысты.
Үз оясын эзләп очып китте,
Карап калдым бары бу кошны.

Агачлардан төшкән сыек шәүлә,
Бер мизгелдә кинәт каралды.
Ялап алды бөтен тирә-юньне,
Саргылт шәфәкъ нуры таралды.

Миллион еллар кояш хозурына,
Җан иясе калмый битараф.
Тылсым көчен кабат күрсәтәсең,
Йокыларга талыр һәр тараф.

Шәфәкъ нуры төште йөзләремә,
Алсулатты мине, кызартты.
Еллар кочагына тагын бер көн,
Күңел моңсуланып озатты.

Таң сузылса,шәфакъ балкыса да,
Мәрхәмәте аның ни хәтле.
Бар назыннан мәңге мәхрүм итми,
Җир анама кояш рәхмәтле.

* * *

# Урманнарга керсәм

Урманнарга керәм бер ялгызым,
Йөрим кошлар дөнъясын күреп.
Аланнарда торам, күз камаша,
Чәчкәләрдән такыя үреп.

Урманнарга керәм серен ачмый,
Атлыйм болан сукмагы буйлап.
Җилфердәтә агач яфракларын,
Күктә кояш нурлары уйнап.

Агачларны кочам колач җәеп,
Юанычлар табып бушанам.
Диңгез шавын әллә ишеттерден,
Урман, сиңа барыбер ышанам.

Урманарга керсәм җан азыгын.
Үзем генә табып сөенәм.
Җил купса да ,давыл кагылса да,
Имән кочагына сыенам.

* * *

# Мин яңалык көтәм ✓

Көнгә керсәм гел яңалык көтәм,
Мәңгелеккә тормый бер төстә.
Җир өстенә яшел үлән шыта,
Ак өстенә кара тап төшә.

Җил тарата куып болытларны,
Ташкын кайта кире ярына.
Күк өстенә җәүһәрләрен сибеп,
Төн җиттеме, йолдыз кабына.

Агач түгә сары яфракларын,
Үз вакыты була,үз чоры.
Безнең заман таш гасыры түгел,
Галәм корабларын очырды.

Еллар алып китә бик еракка,
Ышандырам шуңа йөрәкне.
Хыял көткән, могҗизалар туа,
Яшәү ямьле, яшәү хөрмәтле.

Киләчәгем һаман уйландыра,
Борчылдыра мине үткәнем.
Аянычы,куанычы белән,
Яңа көндә килә көткәнем.

* * *

# Җырларым

Җырларымда бөтен шатлыкларым,
Җырларымда күңел сагышым.
Тормыш юлларына аяк баскач,
Сискәндерде гомер агышым.

Заман гүләвләре колагымда,
Йөрәгемдә җыр-моң ярала.
Сызланганда җаным дәва тапсын,
Нәсихәте тисен ярама.

Бар булмышым җырларымда чагыла,
Шагыйрь өчен шулай тиештер.
Күкләремә күтәр канат куеп,
Бөркетләргә мине тиңләштер.

Сәфәр чыксам җырларымны барлыйм,
Юлдаш итәм,илләр гизәмен.
Шигем бетә, юанычлар табам,
Сихри көче барын сизәмен.

Җырларымда яшьлек хәтирәсе,
Ялгышларым,керсез яшьләрем.
Гөмер буе турылыклы булып,
Сезнең белән бергә яшәрмен.

# Акчарлагым

Көмеш тәңкәләрен сибеп дулкын,
Йөгерә-йөгерә уйный Идел дә.
Идел акчарлагы булгансыңдыр,
Күтәрелдең күңел күгенә.

Чиксез киңлекләргә канат җәйдең,
Күк юллары биек, югары.
Минем кебек җанын фида кылган,
Өзелеп сөйгән кешең юк әле.

Еракларадан карыйм ярларыңа,
Бергә йөргән сукмак күренә.
Гыйшык давыллары ташладымы,
Ялгыз төштем уйлар күленә.

Аккан суларның да яры була,
Уйларымның чыкмым чигенә.
Акчарлаклар булып күңелемдә.
Канат кагынасың син генә.

* * *

## Кулым бушап тормый

Кулым бушап торганы юк,
Балта, көрәк, сәнәктә.
Бар булмышым, уңышымда
Сәбәпчедер сәләттә.

Каләм тотып эш башкармыйм,
Шөгел-фигелем башка.
Чүкеч алып бар көчемә,
Кадак кагам мин ташка.

Тирен түгеп, көчен җигеп,
Күпләр үрләргә менгән.
Хезмәт финишенә киләм,
Яшел әләмен элгән.

Балта тотсам, бура бурыйм,
Көрәк белән җир казыйм.
Тәвәкәллек тырышлыкта,
Уята күңел назын.

Эш коралым әзер тора,
Кирәген сайлап алам.
Фатихасын яшьтән бирде,
Хезмәт күрсәт, ди, анам.

* * *

# Минем халкым

Кемнәр булган минем бабаларым,
Йорт-җирләре кайсы төбәктә.
Юлга чыгам узган ерак чорга,
Сорауларым үзенә ияртә.

Еллар аша, чорлар аша барам,
Көткәннәрем бердә ашыкмый.
Халкым үткән шанлы тормыш юлын,
Тарих битләрендә ачыклый.

Хөрмәтле дә, кунакчыл да халкым,
Белдем аның бөтен гадәтен.
Богауларны, җәберләрне күргән,
Күп сатканнар юкка гайбәтен.

Ачы язмышына баш бирмәгән,
Тәре китергәннәр - үпмәгән.
Игелекле эш кырса да җирдә,
Шатлык-куанычы чикләнгән.

Төрле тарафларга сибелгәнсең,
Туздырганнар ятлар ояңны.
Фаҗигале килгән еллар өчен,
Мин борчылам, нәфрәт уянды.

Кылычың тот кынасында халкым,
Язмышыңа үзең җаваплы.
Ирекле дә, эшлекле дә итеп,
Кешеләрне Ходай яратты.

# Намусыма тап төшмәсен

Намус төшенчәсе яшьтән
Сеңгән икән каныма.
Гаделлек, сафлык, пакълеккә
Җаным ихлас табына.

Намусыма тап төшерсәм,
Рәнҗетер мәгънәсезлек.
Ир-егеткәдә тормышта,
Килешмәс вәгъдәсезлек.

Намусымны калкан итеп,
Күкрәгемә куямын.
Авыр хәлгә тарыганда
Үземдә көч тоямын.

Явызлык кылмыйм кешегә,
Шөкер итәм чын - барга.
Намусым сагында тора,
Тота корыч чылбырда.

Игелек кылалсам икән,
Ватаныма, халкыма.
Вождан газабын кичермәм,
Туры калсам антыма.

* * *

# Яшәвемне раслыйм

Җир шикелле кинәт тетрәп куям,
Йон йомгагы булып сүтеләм.
Бу тормышта яшәвемне раслап,
Дәгъвәләшәм, кайчак үтенәм.

Эчкән суларымның тәме бетте,
Авыр итеп сулыйм һавасын.
Нинди фаҗигале хәлгә җиттек,
Афәт яный адәм баласын.

Таркалганда атомнарың шартлап,
Дарья сыман чайкый җирләрне.
Галәм капкаларын кагып килә,
Давыл юллап йолдыз җилләре.

Заман чире бердә читләп үтми,
Һәр кешегә килеп кагыла.
Икмәгемнән, эчкән суларымнан
Нитрат керә минем каныма.

Иртәгәсе көнне күзаллыймын,
Кайда соң ул безнең кыйбылабыз.
Изгелекне әллә явызлыкны,
Яшәгәндә эшләр кылабыз.

* * *

# Киләчәкне күзаллыйм

Колагымнан китми гөжләп торган,
Заман шау-шуына күнектем.
Аянычлы хәлләр туып тора,
Ихтыяр көч табар кебекмен.

Утлы өермәләр булып дөрли,
Сары шәфакъ ялый күк читен.
Дөнья афәтеннән арынмаган,
Сискәндерде тормыш бик читен.

Күк йөзләрен каплап метеорлар,
Яңгыр булып өскә яумасын.
Нетроннар, атомнарың шартлап,
Газиз җирем көйрәп янмасын.

Боз таулары эреп акса нишләр,
Җиребезне сулар басмасмы.
Җир түгәрәк футбол тубы кебек,
Орбитадан чыгып очмасын.

Мең сорауга бер җавап та тапмыйм,
Томан баскан тоташ күз алдын.
Учак ягам яшәвемне раслап,
Учым белән утлы куз алдым.

Язлар язча, көзләр көзчә килми,
Киләчәгем билгесез һаман.
Сиздерә дә, кисәтә дә сыман,
Әллә җитәме ахры заман?

# Язмышым сокланырлык

Урал урманнарын кистем,
Күмер ташларын ваттым.
Хезмәт җимешемне җыеп,
Олы куаныч таптым.

Бәхетемне эзләп килдем,
Күз күрмәгән якларга.
Авылымны бик сагындым,
Җырлар яздым хатларга.

Өмет белән яшәгәнгә,
Җитә ихтыяр көче.
Авырлыклар күргән саен,
Түземле була кеше.

Тормыш сынауларын үттем,
Сынмадым, сыгылмадым.
Нинди юлларда йөрсәм дә,
Юк, арып егылмадым.

Ата-бабам изге эшен,
Үземә өлге иттем.
Язмышыма сокланырлык,
Булдыклы егет иттең.

# Күрәсем, беләсем килде

Мин тауларның биегенә менәм,
Дарьяларның сайлыйм тирәнен.
Тирәнлеккә, биеклеккә гашыйк,
Әйдәләп гел тибә йөрәгем.

Зәһәр салкыннарда калганым бар,
Кайнар комын капшыйм чүлләрнең.
Ләззәт алып бик сөясем килә,
Бу дөньяның иң бер чибәрен.

Таң нурлары йөзләремә төшә,
Якты учак булып дөрләсен.
Иңнәремдә канат үстерәмен,
Күк юлларын килә күрәсем.

Теләк теләп, өмет багалыймын,
Максатыма барам иң элек.
Күпме эшләр көтә, кулым җитми,
Вакыт кыска, булмый өлгереп.

Күп күрәсем, күп беләсем килә,
Диңгез кичәм, илләр гизәмен.
Ил картлары кебек олы хөрмәт,
Әдәп барын җанда сизәмен.

* * *

# Минем өчен нигъматең күп

Минем өчен кояш көлеп чыга,
Таңнар белән яңа көн туа.
Җаннарымны сабырлата белеп,
Күңелемә дәртле моң тула.

Минем өчен чишмә гөрләп ага,
Бөтен сусауларым басыла.
Урап кайтам сәхрә-кырларымнан,
Иркен кочаклары ачыла.

Минем өчен ап-ак карлар ява,
Кара җир өсләрен агартып.
Ел фасылы гел үзгәреп тора,
Уйларымны һәрчак яңартып.

Минем өчен җирем хазинаң бар,
Алтын тавым, көмеш күлләрең.
Бәхет-шатлык юрап кошлар сайрый,
Хуш-ис сибә асыл гөлләрең.

Минем өчен нигъмәте күп җирнең,
Ризыкларга мул табыны бар.
Кешеләргә ходай ирек куйган,
Оҗмахы да, тамугы да бар.

* * *

# Юлларыбыз очраштырмас

Юлларыбыз башка очраштырмас,
Аерылды төрле якларга.
Син сереңне башкаларга чиштең,
Минем караш төште ятларга.

Намус кушып хөкем чыгарганда,
Газапларны йөрәк яңарта.
Эндәшмәбез, ләммим сүз әйтмәбез,
Кем суксада безнең яңакка.

Гафу үтенергә каламы соң,
Бу тормышны җиңел уйладык.
Тез чүктерде кайгыларын биреп,
Язмыш белән ахры уйнадык.

Башларына карлар, бозлар яуды,
Мин адаштым килеп көзләргә.
Яшәвемне раслап күп мәртәбә,
Ихтыяр-көч таптым түзәргә.

Онытырга теләп ерак киттем,
Тансык түгел барыр юл кемгә.
Яфракларын койган агач сыман,
Тыныч кына карыйм бу көнгә.

* * *

# Мин арыдым

Мин арыдым, көче калмый кулның,
Йокы тапмый төнлә сызланам.
И, чибәр кыз, сиңа барда кызык,
Яшьлек күкрәүләрең узмаган.

Синең күзләр нурлар чәчеп балкый,
Иңнәреңдә чәчең толымы.
Мин, ир заты, сизмичә дә калдым,
Күңелләрем сиңа табынды.

Салкын җилләр сиңа кагылмаган,
Тормыш йөген сиңа салмаган.
Күпме күреп нужна кичердем мин,
Кара чәчләрем дә чалланган.

Көзге алдына килеп басасың да,
Үз-үзеңә карап сокландың.
Эссе чакта, син күләгә таптың,
Салкын булса, көнгә чыкмадың.

Син көләсең, бер дә борчылмыйсың,
Тормыш сынауларың узмаган.
Минем кебек бер кайчан да синең,
Йөрәк-бәгъерләрең сызмаган.

* * *

# Яр башында куш каеннар

Буә яр өстендә куш каеннар,
Колач ачып, җәя канатын.
Җил давыллар килеп кагылса да,
Бер ни булмаган күк тора тын.

Күк күкрәп, яшен яшнәгәндә,
Куш каеннар курка белмәде.
Сәхрә уртасында горур басып,
Үзе белгән җырын көйләде.

Якты таңны шаулы каршылыйлар,
Буә буен күмеп җыр-моңга.
Читләп узмый йөргән сукмакларым,
Шаһит булып яшим мин моңа.

Кулны болгап дәшәм каеннарга,
Еракләрдан күреп танырсыз.
Боз яуса да бердә зарланмыйсыз,
Сеңелләрем кебек сабырсыз.

* * *

# Сандугачлар кайтты

Сандугачлар кайтты бакчабызга,
Сагынгандыр, беләм, оясын.
И, кошкаем, тавышыңнан таныйм,
Туган җирдә шатлык тоясың.

Моң-авазың белән данлыйсыңмы,
Зурлыйсыңмы газиз йортыңны.
Ышанычың артты, бушандың да,
Бөтен булган шигең онытылды.

Талпынасың күкләреңә менеп,
Яшел тирәгеңне сайлыйсың.
Йөрәк өзгеч, ах, моңнарың белән,
Бакчам уртасында сайрыйсың.

Өметләнәм, бозлар булып каткан,
Сары сагышларым эресен.
Узган гомер, үткән юлларым да,
Уйландыра мине төрлесен.

Моңнар дарьясына төшеп йөздем,
Юанычлар таптым, күрәсең.
Заманалар авыр, хәтәр чакта
Хәл белергә миңа киләсең!

# Гомеремнең якты мизгеле

Йөгереп чыгам болын буйларына,
Утлы хисләр җанга кагыла.
Гомернең бу якты мизгелләре,
Хәтер ала барын сагына.

Ярты дөнья гизеп күреп кайттым,
Җанга кирәк җитми матурлык.
Иген кырларыннан якын булган,
Көч тапмадым күңел ятырлык.

Юанычлар, куанычлар табам,
Шөһрәтләнгән сыман бәйрәмнән.
Вакыт агышларын туктатмаган,
Сәхрә-кырлар буйлап әйләнәм.

Сәфәр чыксам әгәр ил гизәргә,
Туфрак салам учлап кесәмә.
Гашыйк булсам һәрбер матурлыкка,
Чама белеп ул да үлчәнә.

Саубуллашып китәм үз иркемә,
Юксынуым бетмәс төшенәм.
Туган җирем иркен, ямен алып,
Күңел түрләренә күчерәм.

# Мин тормышка гашыйк

И, бу дөнья ниләр күрсәтмәде,
Шатлыкларын бирде, кайгысын.
Нигә икән, тормыш, миңа шулай,
Усал күзең белән карыйсың.

Күпме үзең бәхет вәгъдә иттең,
Өметләнәм, һаман мин көтәм.
Татлы хыял, бар ышаныч белән,
Яшьлек язым үтте бик күптән.

Көткән язлар соңлап кына килде,
Сөйгән ярлар калды ятларга.
Сабырлыкны сорап тешне кысып,
Түздем барыбер шундый чакларда.

Нинди генә давыл баштан кичми,
Нинди җилләр килеп какмады.
Киләчәктән көткән ышаныч бар,
Хазина күк йөрәк саклады.

Рухым көчле, тормыш сине сөям,
Уфтанырга һичбер ашыкмыйм.
Тәүге тапкыр унсигезе тулган
Кызлар кебек сиңа гашыйкмын.

* * *

# Кошлар юлга җыена

Вакыт җиткән җыйнаулаша,
Кошлар юлга җыена.
Кызлар кебек күл суында,
Кыр казлары юына.

Кошлар киткән бу мәлдә
Күк юлын торам карап.
Исән-имин туган якка
Кайтыгыз кабат урап.

Елда озатып каламын,
Изге теләкләр теләп.
Аерылу сагышларына,
Ничек түзәргә кирәк.

Мин генәме тирәкләрдә,
Башкайларын түбән игән.
Хушлашасыз моңсулатып,
Китәсез туган илдән.

Кошкайларым сез китәсез,
Оягыз кала ятим.
Ерак сәфәргә чыкканда,
Укып догамны әйтим.

* * *

# Онытырга кирәк

Еллар үтә,
Сизелми дә кала,
Татлы мизгелләрем онтыла.
Вакыт агышында барган саен,
Үткәннәргә күңел омтыла.

Яшермәдем,
Үзем әйткәнем бар,
Онытырга кирәк күпләрне.
Киләчәгем язмыш кулында,
Сагындыра аның үткәне.

Нинди генә йомшак җил иссә дә
Сагынуымны бары көчәйтә.
Йортка төшкән яңа килен кебек,
Ямансулап йөрим кич-иртә.

Урамнарда
Ишетеп җыр тавышын
Йокы тапмый ятам әле дә.
Заманында
Тальян гармун белән
Көлтә кертә идек әвенгә.

Малайларны күрсәм,
Күз алдына килә
Ат саклаган болын буйлары.
Белмим шулай магнит кебек,
Үзенә тарта бөтен уйларны.
Онытырга кирәк бик күпләрне,
Бик күпләрне күңел ятсына.
Ә, кайчакта күктә йолдызларны,
Барысында хәтта юксына.

# Ай тотылган төн

Шом басты тирә-юнемне,
Төн карасы күземдә.
Ай кергән күмер төсенә,
Балкымый күк йөзендә.

Сукмак салып кыр өстенә,
Ай күктә көлеп йөрми.
Абалап авыл этләре,
Бу чакны нигә өрми.

Әллә өнен югалтканмы
Чишмәнең агышлары.
Урамнарда ишетелми
Яшьләрнең тавышлары.

Ходай үзе генә белә
Галәмдә ни буласын.
Өй түрендә шөбһәләнеп
Укый әби догасын.

Сәер дә, серле дә сыман
Ай тотылган бу мәлдә.
Күк ишелеп төшмәсен дип,
Хафага калдым мин дә.

* * *

# Ашыкма, картлык, килергә

Ашыкма, картлык, килергә син,
Тау кадәрле күтә эшләрем.
Хәлсезләнеп, бөкерәеп бетсәм,
Кыл өзәргә калмас көчләрем.

Дөнья ямен, хозурлыгын күрәм,
Ләззәтеннән әле туймадым.
Йөк атлары кебек җигелгәнмен,
Еллар агышында тоймадым.

Юл йомгагым сүтелмичә калган,
Күтеп алам, атыр таңым бар.
Кешеләргә ярдәм кулын сузам,
Бирер шатлыкларым тагын бар.

Хаҗәтем бар үтәлмичә кала,
Алган бирәчәкне бирмәдем.
Көнчел кешеләрне көнләштерәм,
Өрәсе этләр күп өрмәгән.

Гомер үрләренә үрлисем бар,
Җыясым бар хезмәт җимешен.
Вакыт исәпләшми бер кем белән,
Өлгерергә бары тиешмен.

Ашыкма әле, картлык, килергә син,
Җан теләгән - иҗат эшем бар.
Унсигезе тулган егет төсле,
Гыйшык тотып йөргән кешем бар.

# Каен үссен

Каберемдә ап-ак каен үссен,
Булсын миңа якты сердәшем.
Баш очымда басып анам кебек,
Хәлең ничек диеп эндәшсен.

Бөтен гонаһларым ачыкланыр,
Гүрем кысып, шулчак өшетер.
Кабер өстендәге каен гына,
Авыр газабымны ишетер.

Тынлык, караңгылык сискәндерер,
Шәм итәрмен каен яктысын.
Туфрак күмәр, җансыз гәүдәм тынып,
Өнсез генә, беләм ятасын.

Дус ишләрдә, якын туган да юк,
Кем куяр соң чәчкә кабергә.
Каен, сеңлем, сиңа табынырмын,
Җыр-моңнарың белән кадерлә.

Күбәләктәй җаным, өзгәләнеп,
Урын эзләп очар югары.
Мәңгелек йорт ишек, тәрәзәсез,
Моннан чыккан кеше юк әле.

* * *

# Олы юлга чыгам

Тар сукмактан киләм олы юлга,
Көтеп тора алда максатым.
Ерак сәфәр кылган үземне бер
Ялгыз юлаучыга охшаттым.

Киртәләр күп очрый юлларымда,
Сүтеп барам, барын җимерәм.
Зәңгәр офыкларым яулык болгый,
Артка чикмим баскан җиремнән.

Миңа каршы хәтәр җилләр исә,
Аягымнан гына екмасын.
Ышанычым яшәү дәрте бирә,
Афәтеннән ходай сакласын.

Кояшныда чыгармаслар иде,
Күпләр минем белән булашты.
Курыкмадым, өрекмәдем һичтә,
Җыйнаулашып этләр юл басты.

Аякларым тала, юлга атлыйм,
Тирәнәя сулыш һаман да.
Мин төшендем, теләкләргә ирешү,
Җиңел түгел безнең заманда.

# Диңгез чакыра

Диңгез ярларына тәүдә килдем,
Хыялларым күптән чакырды.
Ашкынуым, ярсуларым барда,
Синнән күчкән икән ахры.

Дулкыннар сикерә, уйный, көлә,
Кыя ташларына кагыла.
Сихри моңнар ләззәтенә күнеп,
Күңел кырларыма агыла.

Мәһшүрлеге, көче хәйран итә,
Мин ирләрчә гашыйк - чынлапта.
Диңгез зәңгәрлеге күзләремдә,
Шау-шулары калды колакта.

Израп яткан зәңгәр киңлекләрдә,
Узар юлларымны кисәтте.
Бар гайрәтен, көчен, горурлыгын,
Диңгез ярларында күрсәтте.

Дөнья мәшәкате тынгы бирми,
Яннарыңда калам чак кына.
Дулкыннарың зәңгәр яулык болгап,
Кызлар сыман үзенә чакыра.

* * *

# Син язларны көтәсең

Гомер көзләренә килеп җиттем,
Ә син язларыңны көтәсең.
Көзгеләргә карап елмаясың,
Чәч толымнарыңны сүтәсең.

Сискәндерә, тетрәнү бар җанда,
Күкләремдә болыт таралмый.
Серләремә сердәш булдың, сеңлем,
Минем күңел бикле торалмый.

Сеңлем, синең күзләр очкынлана,
Тирәкләрнең көтеп бөресен.
Кәккүк саный минем елларымны,
Бу чагында уйлыйм төрлесен.

Ачы җилләр тәрәзәмне шакый,
Кары-бозы явып өшетер.
Вакыт үлчәүләргә салып саный,
Авыр кичерәмен ничектер.

Сеңлем, сине ямьле көннәр көтә,
Сүтелмәгән озын юлларың.
Мәхәббәтне, бәхет-шатлыгыңны,
Хыялларың аша юлладың.

* * *

# Күкрәгемдә чишмә моңы

Атам-бабам, нәсел ыруым шигырь язмаган,
Бәхет эзләп ерак юллар буйлап узмаган.
Гомер бакый иген игеп атам көн күргән,
Язмышыннан өстен булып ут-суга кергән.

Атам шөгелен алмаштырдым, гамьсезмен,
Сезгә атап шигырь язган бер ямьсез мин.
Иҗат белән байлык җыеп дача салмадым,
Йөрәк кушты, күңел теле, шуны аңладым.

Шагыйрь халкы мохтаҗлыкта бит гомер сөргән,
Зинданнар да җәберләнеп башы черегән.
Мин фәкыйргә уңнан-суңнан күп таш аттылар,
Көнчелләр нужда калачында ашаттылар.
Гашыйк булдың, йөрәгем, җыр-моңга мең яшә,
Оран салып килер еллар миңа эндәшә.

Шигырь язып, бар дөньяны мин үзгәртәлмим,
Тирән ярага тоз салалар, төзәтәлмим.
Күкрәгемдә чишмә моңы, тургай җыры бар,
Кешеләрне йобатырмын ахы-зары бар.

* * *

# Җирдә яшәр хакым бар

Болыт булып килде кайгыларым,
Баш өстендә яшен яшнәттең.
Һәрчак, тормыш, үгиләттең мине,
Җебер күрсәтеп гел яшәттең.

Гел өстәлеп тора кайгы-хәсрәт,
Күз яшьләрем белән түләдем.
Ходай бирсен сабырлыклар гына,
Ихлас күңелемнән теләдем.

Авызыма капкан ризык бармый,
Урынымда тапмыйм йокымны.
Төнгә керсәм шомландыра мине,
Күктә йөзгән аем тотылды.

Юл йөрергә чыксам адаштыра,
Аерылмадым кыйбла ягында.
Мин мосафир кебек күпне күрдем,
Карасында, дөнья агында.

Аягыма басам бар көчемә,
Юк сүрелмәс, миндә ялкын бар.
Гомер сукмагында ни күрсәм дә,
Җирдә яшәр өчен хакым бар.

* * *

# Мин көч табам

Күз яшьләрен дөнья түктерәсең,
Рәнҗү белән гомер итәмен.
Газабыңны күреп яшәгәчтен,
Нинди рәхим синнән көтәмен.

Этләр туен күреп гомер үтте,
Тормыш ләззәте юк бер төрле.
Ызгыш-талаш белән узган көннәр,
Йөрәгемне талап бетерде.

Юанычлар эзләп карасамда,
Табалмадым аның дәвасын.
Биләүгә дә, кабергә дә сала
Фани дөнья адәм баласын.

Табигатьнең үз кануны белән,
Үскән гөлдә корый вакытсыз.
Гомеремдә күп югалту күреп,
Көйрәп яндым утсыз, ялкынсыз.

Бу заманда яшәү җиңелмени,
Мин көч табам иҗат эшемнән.
Йөрәк кенә түзсен шартламыйча,
Көнчел кешеләрнең үченнән.

* * *

# Адашкан болытлар

Адашып йөргән болытлар
Күк йөзен каплап алган.
Сәер кылана табигать,
Җирем йокыга талган.

Юмарт карга, бураннарга,
Гыйнварнең уртасы.
Салкын җилләрен өрдерә,
Кышның ыжгыр атасы.

Җирдә ап-ак карлар ята,
Энҗе күк ялтырады.
Өшеттерә-күшектерә,
Тәннәрем калтырады.

Көтмәгәндә үзгәрә көн,
Гаҗәп хәл, яңгыр ява.
Уйланмастан шик тудыра,
Саташкан әллә һава.

* * *

## Җыр көйлим

Әз генә сөенечкә дә,
Куанам, канатланам.
Мондый хәл бергенә түгел,
Гомердә кабатланган.

Әз генә көйсәм, борчылып,
Утлар булып кабынам.
Яшен ташы сыман килеп,
Йөрәгемә кагылган.

Әз генә мин хисләнсәм дә,
Сихри моңнарым таша.
Изге уй-теләкләр туа,
Тоемлыйм бер тамаша.

Әз генә җанга тынгылык,
Сабырлык бары телим.
Шатлыгыма, кайгыма да,
Күңелемнән җыр көйлим.

* * *

# Уфа урамнары

Төнен Уфа матурланган,
Күктән алып йолдызлар тезгән.
Якты хыял кочагына кердем,
Уйлар диңгезендә мин йөздем.

ВУЗда укып йөргән еллар чыңлый,
Яшьлек дәрте җанда терелә.
Сокландырып Уфа урамнары,
Дәшә мине мәйдан түренә.

Машиналар чаба, яшьләр уза,
Ташкын гөрли, тынлык бозыла.
Күптән таныш шәһәр парклары,
Гыйшык тоттым Уфа кызына.

Вакыт агышлары тукталганмы,
Чыгалмыймын юлның очына.
Очрашырга барган егет сыман,
Гөлчәчәкләр тоттым учыма.

Әллә дуслар, әллә укыган чак,
Юксындыра,аны еш әйттем.
Бу юлы да Уфа урамнары,
Мине кабат күпкә яшәрттең.

* * *

## Мәхәббәт сүрәсе

Вәгъдәләштек, кул бирештек,
Җәйнең айлы кичендә.
Урман буйлап парлап йөрдек,
Саклыйм аны исемдә.

Бакчадагы чәчкәләрнең
Исләренә исердек.
Безгә бәхет елмаер күк,
Татлы хисләр кичердек.

Теләк изге, максат куйдык,
Башларга тормыш юлын.
Ашкынып йөрәгем типте,
Түгелде күңел моңым.

Ай-йолдызлар шаһит булды,
Расланды бит антыбыз.
Шатлыклы көннәргә илтәр,
Җилдереп туй атыбыз.

Дога итеп кабатладык,
Бу мәхәббәт сүрәсен.
Күкрәгемдә дөрләп янган,
Сөю уты сүнмәсен.

* * *

* * *

***

Йөзләремә көз сарысы чыккан,
Көзгеләргә карыйм сагышлы.
Ыгы-зыгы килеп узган көннәр,
Колагымнан китми тавышы.

Хәвефле елларга туры килдем,
Дөньягамы тудым ашыгып.
Кемгә хәзер аның кирәге бар,
Зарланмадым һичтә ачынып.

Йөгереп чыктым ачып колачны,
Бик яшьтән үк тормыш каршына.
Хыялларым акланмыйча кала,
Мин җаваплы аның барсына.

Киләчәктә дөнья матурланыр,
Өмет итәм әле ямьләнер.
Гел хөсетлек кылган адәмнәр дә,
Казалып бер чалкан әйләнер.

Ышанасың йөрәк үз көчеңә,
Сәер хәлдә калып аңлашам.
Күп үзгәреш, мең кичереш күреп,
Гаделлекне яклап алышам.

# Әни

Офыкларга таң йөгергән, әни,
Самаварың менгән өстәлгә.
Яңа көнгә кергән саен һаман,
Сый-хөрмәтең күбрәк өстәлә.

Җылы икмәк мичтән чыгарасың,
Сыерыңның сөтен савасың.
Табыннарың күркәм, ямьле аны,
Таңнардан син әллә аласың.

Яшәү гаме, гомер куанычы,
Туган туфрагыңа тоташа.
Хыялларың сиңа канат куя,
Шатлыкларың килә көн аша.

Каннарыңа дәрт йөгерә әни,
Яшәвеңнең татлы мизгеле.
Картлыгыңда бәхет колач ача,
Хезмәт сөясең син билгеле.

Үрләр алып менә биеклеккә,
Гомер юлың ята яктырып.
Киләчәккә таба барган саен,
Тормыш яме балкый яктырак.

* * *

# Җанымны кызганмыймын

Елмайган чагымда бар,
Егылган чагымда бар.
Абынган чагымда бар,
Сагынган чагымда бар.

Адашып та йөрдем мин,
Ут-суга да кердем мин.
Таш-кыяга мендем мин,
Яшәү кызык - белдем мин.

Күп төрлегә төрләнәм,
Кошлар сыман кагынам.
Галәм түрләрендә балкып,
Йолдыз булып кабынам.

Җанымны кызганмыймын,
Ихтыярлы көчлемен.
Дөньяны матурларга,
Җиргә туган кешемен.

* * *

# Никтер сулар болгана

Никтер сулар болгана,
Дулкыннар ярга килгән.
Иминлек, куаныч көтеп,
Һәр яңа туган көннән.

Кояшның саран карашы,
Никтер күз генә кысты.
Күктә болыт арасына,
Каядыр кереп качты.

Никтер урман моңсу шаулый,
Колакка тавыш керде.
Үрмәкүч тә бушап тормый,
Ашыгып оя үрде.

Никтер бүген табигатьтә,
Сыкрый, көйсезләнә.
Күзгә күренә кинәттән,
Офыклар төссезләнә.

Никтер җилләр котырынып,
Яннан сызгырып үтә.
Берни булмаган шикелле,
Җир-анам давыл көтә.

***

Гомерлеккә сөйгән ярым син дип,
Саубуллаштың үзең киткәндә.
Очрашырга кабат насыйп булмый,
Шактый гына еллар үткәндә.

Хат-хәбәрең дә юк, билгесезлек,
Вакыт узган саен йончыта.
Кош канаты булса иңнәремдә,
Илләр гизәр идем ничектә.

Кай якларга китеп ояладың,
Күрәсеңдер язмыш язганын.
Кыр казлары кайтса туган җиргә,
Моңсу итмәс мине язларым.

Әле сөяр, сөелер чакларым,
Уй-хисемне кем соң ишетер.
Очырашып та, күрешеп тә булмый,
Тормыш юлы урау ничектер.

Хыялымда һаман, син яшисең,
Йөрәгемдә җәйдең тамырын.
Йолдыз булып балкый бер елмайсаң,
Мин ерактан сине танырмын,
Өмет өзмим эзләп табармын.

# Хозурланам

Сәхраләргә чыгып йөрдем,
Басуларны урадым.
Әйтерсең тәүдә күрәмен,
Офыкларга карадым.

Су буйларына киләмен,
Томаннар таралганда.
Илаһи моңнар агыла,
Сандугач талларында.

Болыннарда озак булдым,
Хозурлыгын тик күреп.
Аллы-гөлле чәчкәләрдән,
Киям такыя үреп.

Һәр төягең, газиз җирем,
Куаныч бүләк иттең.
Кылган изгелек онытылмас,
Туфрагын алып үптем.

* * *

✳ ✳ ✳

***

Көтсәм кайтыр кешеләрем дә юк,
Киткән алар барда кайтмаска.
Алар өчен кояш мәңге чыкмас,
Таңнар да бит тиеш атмаска.

Яшәү кануннарын белсәм дә мин,
Бер могҗиза көтә күңелем.
Сагыш ташып, йөрәгемә сыймый,
Шампан шәрәбе күк түгелде.

Таулар гына өнсез горур булып,
Бөркет сыман җыйган канатын.
Каен үскән кабер өсләрендә,
Моңсу башын иеп тора тын.

Киң галәмдә үз урыным да бар,
Мең кичереш белән күзлимен.
Вакыт агышлары юып алган,
Бер юаныч җанга эзлимен.

Көткән кешеләрем дуслар булса,
Күзләремдә сүнмәс кояшым.
Шигем бетәр, куркуымда калмас,
Көч-ышаныч барын тоясың.

# Авылга кайтам

Елда кайтам авылыма,
Туган җирем кадерле.
Мин анда чәчәкләр салам,
Ата-бабам кабере.

Өзелмәгән тамырларым,
Бәйдә торткан кыллар бар.
Туган ягым чакыра бит,
Миңа дәшкән юллар бар.

Уйландыра, моңландыра,
Чит илләрдә йөрсәктә.
Авылдашлар кайттым исә,
Кадер-хөрмәт күрсәтә.

Ятим калган йорт нигезем,
Бикле килеш йозакта.
Сискәндерә узган гомер,
Яраларны кузгата.

Шәфакъ уты кебек булып,
Сагыш хисе кабына.
Истән чыкмый күңелем,
Туган җиргә табына.

* * *

***

Озак яттың авырып хәлсезсең,
Күтәр әле, әни, башыңны.
Язлар җитте, ямьле көннәр килде,
Бозлар ага, елга ташыды.

Тәрәзәгә торып кара, әнә,
Кар пәрдәсен ачты кырларым.
Рухың төшкән, күңел күтәрерсең,
Ишетерсең тургай җырларын.

Үлем көтеп ятма түшәгеңдә,
Кыр казлары кайта күленә.
Урам читләрендә борын төртеп,
Яшел чирәм шыткан күренә.

Гөрләвекләр тавышы тынмый әле,
Җил тирбәтә агач бөресен.
Өй алдында каз-үрдәкләр йөри,
Их, терелсәң җимнәр бирерсең.

Тормыш йөген сөйрәп яшәгәчтен,
Киләчәккә юллар чакыра.
Язга әни өмет багладың,
Сабыр итсен әҗәл чак кына.

# Тәүдә эш күрсәт

Бу дөньяга күлмәк киеп
Тудым дисең гел генә.
Могҗиза итеп карамыйм,
Мин күрмәдем, кем белә.

Кеше туа анасыннан,
Бер кем төшмәгән күктән.
Чын хакыйкат барын белгәч,
Таныймын аны күптән.

Судан коры чыгалмадың,
Шәп ир-егет булсаң да.
Кылны кырыкка бүлмәдең,
Күлмәк киеп тусаң да.

Айга синдә менәлмәдең,
Тауныда күчермәдең.
Җир кендеге син түгелсең,
Ник һаман төшенмәдең.

Мактарлык эш кыйратмадың,
Кыйблаң кая күчте.
Нәфесең үсте, тәүдә күзең,
Олы кашыкка төште.

* * *

# Соңладык

Очрашырга кичне көтеп алдык,
Төн үткәреп таңнар аттырдык.
Көннәр-төннәр алмашынып тора,
Җанга тансык була матурлык.

Сабырсызлар, тыйнак кыланмадык,
Ашыкканбыз барын татырга.
Соңга калдык, озак айнудык шул,
Үткәннәргә юк юл кайтырга.

Күктә очтык, күктә озак йөрдек,
Кирәк булган җиргә төшәргә.
Адашкан чак, саташкан чак булган,
Берәм-берәм керде төшләргә.

Кызык күреп көлеп кенә йөрдек,
Үткәнмедек, тәүбә итмәдек.
Яман эшне үлчәүләргә салып,
Сират күпереннән үтмәдек.

Соң төшендек, арттан калмый йөри,
Кара күләгәләр шуыша.
Игелекле, куанычлы эшләр
Тал бөресе кебек тулыша.

* * *

# Аңлаштык

Йөзең чытык, кәефең юк,
Уйчанланган күзләрең.
Җәрәхәтли йөрәгеңне,
Уйнап әйткән сүзләрем.

Рәнҗүеңне сиземләдем,
Карашыңны күзләдем.
Әллә гамьсез кыландыммы,
Гаебемне эзләдем.

Ут алган учак шикелле,
Дөрләп кабынып киттең.
Ачуларыңны сүрелтеп,
Кочып битеңнән үптем.

Юктан низаг чыгардыкмы,
Нервыларны кузгаттык.
Төрле уйларны кичердек,
Күңелләрне сызлаттык.

Үпкәләштек исәпләшми,
Төшләнепме адаштык.
Аның туры юлын таптык,
Бәхәсләштек, аңлаштык.

* * *

## Еллар һәм юллар

Арба тәгәрмәче сыман,
Алга тәгәри еллар.
Киләчәккә чакырып тора,
Бормалы озын юллар.

Юлларым сүтелеп кала,
Кем чыгалыр очына.
Зәңгәр капкалар шикелле,
Офыкларым ачыла.

Елларым белән юлларым,
Үрелеп бергә бара.
Кеше гомере санаулы,
Еракмы барыр ара?

Җилләр исә, сулар ага,
Йөрәк майлары сыза.
Күренми дә, сизелми дә,
Юлларда гомер уза.

* * *

## Күңелемдә яз

Кар сулары челтер-челтер ага,
Тау битенә карыйм - ачыла.
Күкләр аяз, болыт әсәре юк,
Караш төшә офык очына.

Миңа тансык ташу сулар шавы,
Җиргә шыткан яшел чирәме.
Урман-кырлар уяналар инде,
Тирәкләрем серен сөйләде.

Биләүләрдә агач бөреләре,
Сөеп кенә җилләр тирбәтә.
Яз кешегә сөю алып килә,
Кабул булды минем теләк тә.

Җирнең төсе, яме арта бара,
Кабатланып тора гомергә.
Назларыңнан мине мәхрүм итмә,
Югалтласы килми һич бер дә.

Илгә кайтты кошлар ерак яктан,
Күңел түрләренә юл алды.
Сагышларым, шәүлә булып кына,
Күз алдымнан китеп югалды.

* * *

# Алыш

Яшәр өчен дәгъвалəшәм,
Якалашам, алышам.
Ир уртасына җиткәнмен.
Сынатмаска тырышам.

Тормыш белән алышканда,
Тәгәрим, төшәм түбән.
Өскә үрләгән чагымда
Күккә тиядер түбәм.

Канатсыз кош хәлендәмен,
Юк, китәлмим качып та.
Хаксызлыкны күргән саен,
Бәгырь әрни, ачыта.

Авыр йөкләр иңгә ята,
Килмәсә дә көчемнән.
Мин гаепле булмасам да,
Ояламын кешедән.

Дөньяның бар матурлыгын,
Күреп яшәргә кирәк.
Таш ватыла, корыч сына,
Ышанам, түзә йөрәк.

Җил-давыллар каршы исә,
Аягымнан екканчы.
Тормыш белән алышырмын,
Тәннән җаным чыкканчы.

# Шикләнеп карыйм

Көтмәгәндә гүләп давыл куба,
Бер сулышы ега аяктан.
Кешеләрнең көчсезлеген күреп,
Җан сыкрый, рәнҗиояттан.

Бер карасаң акыл көче җитә,
Ерак йолдызларга юл сала.
Мин ышанам, яшим кешеләрчә,
Өмет уты сүнми, иншалла.

Билгесезлек сер пәрдәсен ачмый,
Ничә төрле сорау тудыра.
Үз җавабын һәркем көтеп ала,
Уйлар тынгысызлый, туйдыра.

Тәрәзәдә чебен безләсә дә,
Жу итәсең, йөрәк, сискәнеп.
Нинди һәләкәткә юлыктык, дип
Баскан җирдә торам шикләнеп.

Көнен-төнен җәбер-золым яный,
Шаһит булып моңа төшендем.
Гамьсезлегеме соң чиктән ашкан,
Көчсезлеге әллә кешенең.

* * *

# Язмыш сынавы

Утлар булып дөрләп янам,
Сулар булып түгеләм.
Мин тормышта яраланып,
Тагын үзем терелэм.

Ташкан сулар кебек шаулы,
Болганчык замансы.
Мескен хәлендә түгелмен,
Һич килми зарланасы.

Яшәгәндә мохтаҗлыклар,
Адым саен кисәтә.
Бу дөньяга кунак булып,
Азга гына килсәк тә.

Язмышлар якадан алып,
Башымны җиргә ора.
Өзгәләнәм, сызланамын:
Гомерләр үтә тора.

Баш өстендә күк күкри,
Камчылый яшеннәрең.
Сабырлыгымны җыеп мин,
Күз яшен яшерәмен.

* * *

## Чияләр пешкән

Бакчаларымны ямьләде,
Алланып чия пешкән.
Шәфакъ нурын, таң балкышын,
Иртәсен, кичен эчкән.

Бриллиант ташы диярсең,
Тәлгәшендә чияләр.
Учларыма җыеп алам,
Мөлдерәмә чибәрләр.

Чияләрем ширбәтләнгән,
Йотарлык телләреңне.
Быелгы җәй сөенечле,
Үтәде теләгемне.

Уты-ялкыны бар сыман,
Кулыңны алыр өтеп.
Тәлгәшен түшеңә тагып,
Йөрерлек бизәк итеп.

Хозурлыгы табигатьнең,
Җәйләрнең ямьле мәле.
Иреннәремдә калырлык,
Чияләремнең тәме.

* * *

# Кәнтәй

Ирең, балаң барын уйламыйсың,
Хыянәтче булдың гаиләңә.
Ничек, гарләнмичә, каш сикертеп,
Ир затына килеп бәйләнә.

Нәфсе колы булып яшәгәчтен,
Төн уздырдың ятлар куйнында.
Шөһрәтләнә җаның ләззәт таба,
Азгынлык бар синең каныңда.

Әдәп сакламадың гомереңә,
Игелекле эш тә кырмадың.
Ыштаныңны иртән тапмасаң да,
Ирләр рәтсез диеп хурладың.

Танымыйсың кылган гонаһыңны,
Яман эшләр белән отылдың.
Чәчләреңнән сөйрәп тукмадылар,
Күпме ирләр белән тотылдың.

Оят барын белеп яшәмисең,
Йөгән салган, нәсел биясе.
Син кәнтәйгә адәм актыгы дип,
Хак сүз әйтер әле берәрсе.

* * *

# Офык аша уза юлларым

Күкне җиргә тоташтыра киңлек,
Еракларда зәңгәр сызыкка.
Җирне аркылысын буйлап чыктым,
И, бу дөнья бигрәк кызыкта.

Офык аша уза борма юллар,
Күтәрелә яңа үрләргә.
Нинди генә болыт өскә килми,
Нинди җилләр исми ирләргә.

Утына да керәм, суына да,
Тешләремне кысам күп чакта.
Юл газабын, мәшәкатен аның,
Үзем белән йөртәм капчыкта.

Җил сызгыра, яшен чатнап уйный,
Җан өшеткән әллә дәһшәт бар.
Үткәннәрем кире кабатланмас,
Киләчәккә куйган максат бар.

Уңга китсәм гел уңармын төсле,
Сулга китсәм никтер уйлата.
Кырык якта, кырык язмыш көткән
Киләчәккә барыр юл ята.

* * *

# Син кабызган утлар

Елга ярын
Күксел томан япкан.
Су өсләре шундый тын иде.
Тәүге тапкыр
Без күрешкән чакта,
Ай елмайган якты төн иде.
Яшьлегемнең кабатланмас язы,
Исерттеме әллә матурлык.
Су буенда йөрдек,
Бакчаларга кереп,
Гөлләр арасында утырдык.
Ә син, иркәм,
Сизмәдеңме шунда,
Күңел тынычлыгын югалттым.
Карашларың
Җилкендерде, шаштым,
Йөрәгемдә давыл кузгаттың.
Нинди татлы яшьлек мәхәббәте,
Бер күрүдә гашыйк итәрлек.
Син кабызган утлар күкрәгемдә
Гомер буе сүнмәс, җитәрлек.

* * *

# Соңлама син

Татлы уйлар кайнар хисләремдә,
Сыярмы соң язган хатыма.
Изге теләкләрем кабул булсын,
Матур киләчәгең хакына.

Әйтер сүзем кала әйтелмичә,
Кыюлыгым гына җитмәде.
Телем белән аңлатырга читен,
Күз карашым сөйли күпләрне.

Таң елмая, аккош канат кага,
Җилләр үбә сөеп битемнән.
Вакыт уза һаман күрешәлмибез,
Син онытма мине, үтенәм.

Иңнәреңә төшкәч чәч толымың,
Тасма юлларыма охшатам.
Зәңгәр яулык болгап озатып калдың,
Күзләремне алмыйм офыктан.

Ара ераклыгы шикләндерми,
Уйларымда сүнми каласың.
Төн җиттеме йолдызларга карыйм,
Өй турымда балкып янасың.

Сабырлыгың җитсен очрашырбыз,
Чын мәхәббәт шулай сынала.
Мин кайтырмын якты таңнар булып,
Каршыларга синдә соңлама.

# Җәй көннәре

Җәй көннәрен тансык күрәм,
Җиргә төшә күләгә.
Бакчаларда түтәл-түтәл,
Сулар сибәм гөлләргә.

Яшәү куанычы арта,
Йөрәк тибә егәрле.
Тугайларга сукмак салам,
Пешкәч каен җиләге.

Энҗеләр күк җем-җем итә,
Чык бөртеге ялтырап.
Тирә-юнем балкып тора,
Җәй көннәре яктырак.

Табигатьнең уяу чагы,
Һәр тарафта җанлылык.
Таңнар шәфаккә тоташа,
Бер могҗизә яңалык.

Сәхрә-кырларга чакыра,
Бу мәлдә кем чыкмаган.
Ямен, назын, хозурлыгын,
Җәй көннәре саклаган.

* * *

# Язлар көлеп килә

Тышта апрель,
Күк йөзләре аяз.
Кояш көлә, кояш елмая.
Кар сулары шаулап ага,
Тын басулар тагын уяна.

Назлы җилләр,
Яз хәбәрен китерә.
Челтәрләтте ап-ак карларны.
Кеше күңеле кебек ярсып тора,
Ташып чыга елга ярларын.
Күк астында шәрә
Таулар ята,
Борын төрткән таллар бөрегә.
Ямьле мизгел,
Матур бу чак,
Туры килде минем гомергә.

Ил өстенә,
Якты язлар килә.
Кеше күңелләрен яшәртә.
Тормышыбыз кебек гүзәлләнә,
Җир өсләре күмелә чәчәккә.

⁂

# Тормыш упкынына ташланмам

Күңел күзен
Гомер юлларына төбәп,
Узган елларымны санадым.
Бар шатлыкка, биш кайгыны биреп,
Тормыш, мине мең кат сынадың.

Әзме, тормыш
Дулкыннары какты, сукты.
Утка салды, суга ташлады.
Таулар өйсәң күккә тияр хәтта,
Мин чыгарган күмер ташлары.

Яшьлегемнең шыткан бөреләре,
Чәчәк атты күмер базында
Бәхетлемен
Әгәр хезмәт җимешләрен,
Алып килсәм тормыш язына.
Килер көннәр имин генә булсын,
Якты өмет белән шатланам.
Мин тормышның һәр вакլыгын күреп,
Упкынына аның ташланмам,
Ихтыярга, көчкә ышанам.

* * *

# Планетада җиңү бәйрәме

Кырык бердә
Җырлап ирләр китте.
Онытмыймын шаулы иртәне.
Күңел кыры һаман бушап бара,
Хәтер саклый әле күпләрне.

Ул чагында дошман явы килде,
Сөремләнде офык читләре.
Канга сусап улап чыкты,
Чик буеннан фашист этләре.

Ата улын,
Инә кызын озата.
Мәһшәр көнне әллә шул чаклы.
Сафлар булып көрәш мәйданына,
Күтәрелә бөтен ил халкы.

Ташкын булып
Ургып нәфрәт таша.
Йөрәк сыкрый, күңел яралы.
Һәрбер кеше
Ил язмышын
Үз язмышы итеп карады.

Тез чүкмәгәч
Палач балтасына,
Ихтыяр да, көч тә җитәрлек.
Көрәш кырын узган
Ал байракны
Рейхстаг өстенә үк күтәрдек.

Тарих белми
Мондый каһарманлык,
Һәйкәлләрдә чәчкә бәйләме.
Планеталар буйлап аваз сала,
Тантаналы җиңү бәйрәме.

# Ялгыз кош зары

Шәфакъ нуры юды җир өсләрен,
Зәңгәрләнде төннең пәрдәсе.
Кызлар кебек купшылана каен,
Маңгаена төшкән бөдрәсе.

Үзәннәргә таман челтәр суза,
Шау-шулары җирнең тынада.
Төн җиттеме шул каенга,
Ялгыз кошчык очып кунада.

Төннәр буе сайрый канат кагып,
Ах-зарлары чыга йөрәктән.
Югалткандыр бәлки үз газизен,
Язмыш китердеме ерактан.

Чишмә кебек чыңлап моң тарала,
Сагыш та бар монда, зар да бар.
Яшьлек мәхәббәте, гашыйк уты,
Сагыну хисе анда - бар да бар.

Бар табигать моңсу тынып ята,
Аңлый төсле аның моң-зарын.
Моңланасың кошым, зарланасың,
Беләсең бит
Төн артында якты көн барын.

# Игенчеләр көткән көн

Күк астында
Аккошлар кебек тезелеп,
Аккаеннар тора бөредә.
Җирне япкан
Бәрхет төсле күренә
Яшел уҗым басу түрендә.

Гүзәл күренеш
Дулкын-дулкын
Буразналар үтә сузылып.
Нинди серле көчләр белән
Алсу таңнар атты сызылып.

Мин кызыгып карыйм,
Зәңгәр күккә, зәңгәр күзләргә.
Карашларым
Нигә уйчанлана,
Уйчан кеше саран сүзләргә.
Иген кыры,
Үзенә дәшеп тора,
Йөгереп килер төсле каршыма.
Тургай җыры, мотор гөрелтесе,
Өн-авазлар бергә кушыла.
Кояш назлый
Көлтә-көлтә нурлар агыла,
Үлән өсләрендә чык ята.
Бар табигать кенә түгел,
Бар кешелек
Хезмәтенә мәшгуль чынлыкта.
Иртә белән тракторлар гөрли,
Ал байраклар элгәч күк чите.
Көнне төнгә бәйли торган
Игенчеләр көткән көн җитте.

# Тәрәзәмне ачтым

Иңнәренә ачтым тәрәзәмне,
Искән җилләр сирпеп кагылды.
Авыл өстен төн пәрдәсе каплый,
Җем-җем итеп утлар кабынды.

Тасма кебек бормалы юл уза,
Томан төшкән уйсу урыннан.
Киң кырларны моңлы җырга күмеп,
Печәнчеләр кайта болыннан.

Тәрәзәмнән кергән кыр җилләре
Иңнәремнән назлап кочтылар.
Җыр-моң бүләк итеп печәнчеләр
Күңел пәрдәләрен ачтылар.

*  *  *

# Азгынлык

Кичә синдә озак кунак булып
Төн уздырып кайттым өемә.
Шәраб шаукымына каным кызып,
Шапырындым аның көенә.

Ирләр халкы ялгыз хатын күрсә,
Төшергәндә булса, җебенсә.
Ничектер бер бушанырга теләп,
Сулыш ала шулчак, җиңелчә.

Җәннәт кошым, карлыгачым, диеп,
Кызган баштан сине мактадым.
Иртән күзне ачкач, бик үкендем,
Гафу ит син, диеп акландым.

Җанга оялаган азгынлык бар,
Нәфсегә дә без чик куймадык.
Ләззәт табып, мәхәббәт уенын,
Төн узганны сизми уйнадык.

* * *

# Кайтсам

Алмагачлар чәчәк аткан мәле,
Сайрар кошлар канат кагына.
Малай чакның хәтирәсен саклап,
Кайтам әле туган ягыма.

Узган юллар, йөргән сукмакларым,
Яшьлегемә мине әйдәде.
Туган җиргә, юмарт туфрагына,
Күңел кылларымны бәйләде.

Кайтсам таулар канатына басам,
Тансык итеп сулыйм һавасын.
Туй атлары ярсып чаба мени,
Дарья суың чыңлап агасың.

Акчарлаклар баш өстеннән оча,
Дулкын ага күлләр читенә.
Хозурланам, ямьле чаклар әле,
Толым-толым уйлар сүтелә.

Сәхрә-кырлар барда уяу тора,
Болыннарда печән покосы.
Туган җирем сый-хөрмәтең олы,
Тәмле аның үлән какысы.

Сагынганда сусавымны тоям,
Сабырлыкта җитсен чак кына.
Үткәнем бар, киләчәгем көтә,
Икеседә мине чакыра.

Туган якта куанычым арта,
Тарту көче барын тоямын.
Тугайларда җиләкләрең пешкән,
Учларыма өзеп җыямын.

# Нәрсәдер җитми

Әллә ирлек, әллә хөрлек җитми,
Тешләп булмый бердә терсәкне.
Гамьсезләр күп, юл чатында торган,
Эт шикелле телен күрсәтте.

Азгынлыкны һаман алга сөйри,
Туй ясыйлар качып почмакта.
Ата-аналар үз баласын барын,
Шәйләмидә, белми бу чакта.

Ыгы-зыгы, вак төяге бетми,
И, шау-шулы безнең замана.
Иртән торсаң, ир хатыны өчен,
Хатын ире өчен зарлана.

Дөнья тулы ирсез хатын йөри,
Теләгәнчә барда типтерә.
Кафе залларында бу кәнтәйләр,
Кети-кети танго сикерә.

Ак перчатка киеп тост күтәрә,
Зәм-зәм суын мактап эчәләр.
Үз кадерен сатып кайда гына,
Төн уздырмый хәзер бичәләр.

Дәрәҗәле олы абзыйлар да,
Җаен көтеп нәфсе аздыра.
Ата улын, инә кызын белми,
Булган гаиләсен туздыра.

Эч пошыра, сәер ялтыраулар,
Кызыктырмый арзан бизәктә.
Җаның сусаганда, наз булырлык,
Шөһрәт табалмыйсың эзләптә.

***

Диңгезләрнең тирәненә кызам,
Йолдызларның сайлыйм яктысын.
Урап чыгам континентлар буйлап,
Төн чыкканчы дөнья яртысын.

Төрле илдә, төрле телдә сөйли,
Барысыда булсын дусларым.
Ерак ара чакырымнарын тезә,
Канатлары тала кошларның.

Максатыбыз уртак, теләкләр бер,
Дуслык җебе бәйли хисләрне.
Безне бергә очраштырган чакта,
Исбатлана тарту көчләре.

Кешеләр бит төрле хезмәт сөя,
Чәчә, ура, иген үстерә.
Биек таулар аша юллар сала,
Кыю булгач таулар күчерә.

Хезмәт тантанасы куанычлы,
Миндә калмыйм аннан өлешсез.
Җир уллары каһарманлык кыла,
Күрми, белми яши белексез.

Татлы хыялларым чынга аша,
Күпләр кебек гашыйк иҗатка.
Һәйкәл куяр, замандашлар шаһит,
Мәрмәр ташын бизәп ир-атка.

# Гармун уза

Шәфакъ батты,
Төн пәрдәсен япты.
Чык бөртеге кунды гөлләргә.
Яфрак кына кайчак калтырана,
Ай шәүләсе төште күлләргә.

Ялгыз каен
Күл буенда тора,
Маңгай бөдрәләрен таратып.
Гармун уза, гармун йөри,
Авыл урамнарын уратып.

Ул күтәрә күңел пәрдәләрен,
Чиртеп үтә йөрәк кылларын.
Ямьләндерә яшел тугайларны,
Җанландыра иген кырларын.

Уйландыра гармун, моңландыра,
Ташкан хискә бирелеп торамын.
Бар иде бит шулай,
Гармун уйнап
Йөргән чаклар авыл урамын.

* * *

## Шундый хәлләрем була

Кыл өзәрлек хәлем калмый,
Әйтерсең сабый бала.
Эштән кайткач өнсез калган,
Шундый мәлләрем була.

Көн буена тир түккәчтен,
Төн кочагына ала.
Мәшәкатьләрем онтылган,
Шундый мәлләрдә була.

Таң көлеп уята мине,
Тирә-юнъ нурга тула.
Күңелемә хуш китергән,
Шундый мәлләрем була.

Иртән чыгам кырларыма,
Көчем таша, дәрт туа.
Хезмәтемнән илһам алган,
Шундый мәлләрдә була.

Кояш шаһит игенчегә,
Ышандым күптән моңа.
Тургайлар җыр бүләк иткән,
Шундый мәлләрем була.

* * *

***

Әвәсләнеп ләззәт алып башта,
Малайлар күк ихлас уйныйсыз.
Моның нәтиҗәсен белмәсәктә,
Кызык итеп, кыска уйлыйбыз.

Уйнап кына тәүдә хәмер кабып,
Күңелләрне күккә күтәрдек.
Көчләр ташып, хисләр дулый,
Җирнең читенә үк итәрлек.

Уйнап кына бәхәс кузгаткачтын,
Чикәләштек гауга чыгардык.
Якалаштык йодырыкны төйнәп,
Кул күтәрдек инде чынладык.

Кызык итеп сигар суырабыз,
Төтеннәрен җилгә таратып.
Ирләр халкы үзен күрсәтәме,
Уен уйный имеш яратып.

Иләс-миләс гомер узып бара,
Уйнап кына эшләр башкарып.
Хәләкәткә барып җиткәч кенә,
Башны булмый шул ташка орып.

# Яз

Җир уянды татлы йокысыннан,
Ачты әкерен ап-ак юрганын.
Яз кояшы шәфкатъ нуры белән,
Такырлады сукмак юлларын.

Керфекләрен кага ак каеннар,
Бөреләнә, кабат яңара.
Йөрәкләрне җилкендергән хисләр,
Ташкын булып акты даръяга.

Офык ишекләрен ачкан сыман,
Сихерләнде җаным таңнарда.
Табигатьтә сизәм җанлану бар,
Сандугачлар сайрый талларда.

* * *

## Күл өстендә тынлык

Күл өсләрен күксел боз каплаган,
Аккош түккән ярга мамыгын.
Ап-ак җәймә кебек җәйрәп ята,
Бер караштан күреп таныдым.

Сагышларга төшеп күл камышы,
Бәргәләнә җилгә сугыла.
Дулкыннарның чыңлап уйнап йөргән,
Шанлы чагын ахры сагына.

Сәер тынлык сарган яр буйларын,
Ишетелми монда өн-тын юк.
Үлән шиңгән, агач яфрак койган,
Югалган шул җәйге матурлык.

Бер чеметем мамык җирдә ауный,
Аккош куйган назын, җылысын.
Тылсым көче барын күреп тордым,
Күңел яраларын юасың.

Аваз салам ерак офыкларга,
Кайтавазың кайда йотыла.
Мин ишетмим җир сулышын бүген,
Бар тирә-юнь тынган йокыга.

* * *

# Мин ишетәм шагыйрь җырларын

Иңләп-буйлап йөрдем,
Томбов урманнарын.
Озын сукмаклардан атладым.
Күпме генә йөресәмдә инде,
Сөйгән шагыйрь сине тапмадым.
Карашларым
Ерак офыкларга җитми,
Каеннарның үрлим башына.
Урман юлларыннан,
Алан чәчкәләрен җыеп,
Такташ килер кебек каршыма.
Белмим
Әллә күңел юксынганга,
Урман аланнарын эзләдем.
Ул кайдадыр бик якында төсле,
Уелып калган җирдә эзләре.
Мин көтсәмдә, кайтмас
Бунтарлыгы,
Алып киткән икән гомергә.
Язлар саен көтте ак каеннар,
Сагынып беткән аны күрергә.
Ул калдырган җырны онытмаган,
Таулар, күлләр, зифа камышлар.
Борма юллар, урман аланнары,
Барда монда аңа танышлар.
Каен кызы,
Усак егетләре моңлы.
Озак йөрдем урман юлларын.
Һәр авазга туктап колак салам,
Гүя ишетәм
Такташ җырларын.

## Сәхрәләргә чыксам

Ялгызлыкка мине күндермә син,
Өметләндер әле ичмасам.
Ышанычым соңгы терәгемсең,
Ни хәл итим әгәр ташласаң.

Юл чатында баскан ак каенны,
Ялгыз үскән өчен иш итәм.
Миңа кушып әллә җырлыйсыңмы,
Җыр-моңыңны һәр чак ишетәм.

Сәхрәләргә чыгып хушлашамын,
Күксел тауларыма эндәшәм.
Сагышланам, хәсрәтләрем арта
Бик азга да түзмим күрмәсәм.

Кошлар сайрый, монда табын җыя,
Телләрен дә аңлыйм, отамын.
Яшел үләннәрне юрган итеп,
Малайлар күк аунап ятамын.

Урман-кырларымда ялгыз йөрим,
Әйтерсеңлә килэм кунакка.
Сәхнәләрдә бердә ишетмәгән,
Симфония керә колакка.

* * *

# Дим ярында

Дим буена, мәгърүр ярларына,
Тәүге тапкыр килдем гомеремдә.
Агым суларыңның зәңгәрлеге,
Гашыйк итте мине күрәмдә.

Йөгерек дулкыннарның моңлы шавын,
Бала чактан тыңлап үсмәдем.
Тирләп эштән кайткан чакта,
Учка салып суын эчмәдем.

Бөркетләрең кунган яр башына,
Кулларымны куям кашыма.
Ак дулкыннар көлеп сәлам бирә,
Йөгереп килә күреп каршыма.

Дим сулары кочагына алып,
Күкрәгендә сөеп тибрәтте.
Карлыганнар өздем тугаенда,
Иренемдә калды ширбәте.

Хуш ис сипкән йомшак үләнеңдә,
Рәхәт икән, ятып аунадым.
Ярсу хисләремә дәрт өстәдең,
Ашкынуың барын аңладым.

* * *

## Киләчәккә кала ышанычым

Апрель таңын көтеп каршы алдым,
Кайтавазлар микән чыңлады.
Урамнарда эри күксел бозлар,
Сыерчыклар быел соңлады.

Киләчәктә бөтен өметләрем,
Кабул итми күңел башканы.
Бу дөньяның юктыр дарьялары,
Минем уйлар кебек ташканы.

Бушаганмы әллә юллар очы,
Җан иясе никтер ашыкмый.
Тизлекләрне тизлек алыштыра,
Уй-фикерне акыл ачыклый.

Көч-хәрәкәт җанда арта сыман,
Җир сулышын тоям якынсың.
Ышанычым якты язлар белән
Киләчәктән миңа кайтырсың.

Зәңгәр күкләр көтә кыр казларын,
Ихтыярсыз, белми чаманы.
Көтүләре озак тоела шул,
Минутыда аның санаулы.

* * *

# Агачларга үрли сарылык

Оеп кына, тынып кына тормый,
Агачларга үрли сарылык.
Табигать бер мизгелгә генә,
Җитсә икән сиңа сабырлык.

Җанга рәхәт алсу таң елмайса,
Күктә балкып көлсә кояшың.
Җирнең назлы барлык чәчкәләре,
Сыйдыралмас аны кочагым.

Ачы җиле, салкын кыраулары,
Йөрәк тетрәр бер үк тимәсен.
Күкрәп яусын ләйсән яңгырлары,
Мин саклаган гөлләр шиңмәсен.

Аккошларны озатып калыр тиздән,
Башын иеп күлләр камышы.
Хушлашырга вакыт җитә икән,
Ишетелә казлар тавышы.

Мәшәкатьләр артып торган саен,
Кысык тоела тагын бу җәем.
Гомер узып бара вакыт җитми,
Гел кисәтә табып үз җаен.

Офык читләренә шәфакъ йөгерә,
Учак дөрли сыман күренә.
Сары көзең килеп малайлар күк,
Агач башларына үрелә.

# Вакыт җитте

Туган илем, торган җирем синдә,
Имин генә булсын киләчәк.
Бөтен дөнья вакыт хөкемендә,
Яңа елга атлап керәчәк.

Вакыт җитте, көмеш чаңын кага,
Буран уйный, карлар тузына.
Күктән иңгән тоташ ак пәрдәсе,
Ерак офыкларга сузыла.

Аклык-сафлык җанны сөендереп,
Тормышка ямь, нурлар өстәсен.
Юлларымны бүлгән киртәләрне,
Бу юлы җимереп сүтәрсең.

Ил күәте, даны кайтсын - тизләт,
Халык ышанычы аклансын.
Изге теләк белән канатландык,
Афәтләрдән Ходай сакласын.

Йорт-җиремнең бәрәкәте артсын,
Дәртләндерсен хезмәт җимешем.
Табыныма дусларымны җыям,
Бәйрәм каршыларга тиешмен.

* * *

* * *

***

Каян килә әдәпсезлек,
Каян килә әрсезлек.
Кешене бер күргәчтендә,
Карашыннан да сиздек.

Эт кырында эткә охшый,
Песи янында мырлый.
Аның гына сүзе үтә,
Үз җырын гына җырлый.

Маймыллана, и кылана,
Белми дә кыйбыласын.
Фиргәвенгә, шайтангамы,
Кемгә соң табынасың?

Уңны, суңны аермыйсың,
Комнан аркан үрәсең.
Ятсаңда стена аша
Бар дөньяны күрәсең.

Үз юлыңны табалмыйсың,
Абындың да сугылдың.
Яңадан туарга кирәк,
Ах, анаңны сагындым.

***

Еллар алып китте яшьлегемне,
Кайда калды чая егетлек.
Тормыш ваклыгына алдандыммы,
Егетлекне әллә череттек.

Яшьлек үзе үтмәгәндә сыман,
Ул кайдадыр кебек якында.
Күңел ярсый ташкын хисләргә,
Йөрәк көйри һаман ялкында.

Яшьлегемне эзлим, табармын күк,
Элек йөргән борма юлларны,
Сандугачлы язгы таңнарымны,
Җилкендергән дәртле җырларны.

Тик табалмам үзен яшьлегемнең,
Ул калган шул биктә еракта.
Гүзәл мәлнең якты хәтирәсен
Саклап яшим аны йөрәктә.

# Борчылма син, ана!

Йөрәк җылын кызганмыйча, ана,
Хатлар яза сөйгән улына.
Иртә-кичен күңел көтәдер,
Күзен сала кайтыр юлына.

Ана күңеле сизә, алдан белә,
Солдат мохтаҗ сәлам хатына.
Ил чигендә сакта тора бүген,
Керфек какмый Ватан хакына.

Кабынмасын җирдә сугыш уты,
Түгелмәсен бердә кайнар яшь.
Тыныч булсын илләр, кояш көлсен,
Мәңге сүнмәс якты нурын чәч.

Солдат поста, күз карасы кебек,
Иминлеген саклый ананың.
Аңа бәйле гомер озынлыгы,
Һәм бәхете сабый баланың.

Борчылма син, ана, солдат улың,
Тап төшермәс изге антына.
Ышанычны аклар, өмет белән,
Хезмәт итә илем халкына.

* * *

## Мөмкин булса аңлашу

Узган юллар артта калган безнең,
Йөргән сукмаклар да суынган.
Аянычлы булса аерылулар,
Үкендерә икән соңыннан.

Безнең арабызда ята еллар,
Бер-беребездән шактый еракл ар.
Ник күңелләр генә тынычланмый,
Очрашыргамы соң теләк бар.

Очрашкан чакта сер бирмибез,
Таш бәгерле нинди кешебез.
Керфекләрне яшькә манчытабыз,
Кайвакытта сабый төслебез.

Нигә кирәк шулай газапларга,
Күңел сынык, йөрәк яралы.
Вакыт дарьясында йөзгән саен,
Ерагайта икән араны.

Өмет учаклары сүнмәгән ич,
Мөмкин булса әгәр аңлашу.
Гомер узган саен уфтандыра,
Булмас иде болай ямансу.

* * *

# Үрмә гөлең булам

Тәрәзәңдә челтәр пәрдәләре,
Челтәреңә гөлләр үреләә.
Ишетәсеңме сөю сагышымны,
Өй турында җырлар түгелә.

Гөлләреңә кайчан су сибәсең,
Карашыңны синең күрмәдем.
Күзләремне төбим тәрәзәңә,
Сабырлана белми йөрәгем.

Гөлләреңне күреп сокланамын,
Гүзәллекнең белеп кадерен.
Тормыш сукмакларын бергә үтик,
Чынга ашсын теләк бәгерем.

Уйларымны, йөрәк серләремне,
Күзләремә карап күрерсең.
Үрмә гөле булып мәхәббәтем,
Тәрәзәңә синең үрелсен.

* * *

# Дөнья өйрәтте

Рәхмәт төшсен димен бу дөньяга,
Күп нәрсәгә мине өйрәттең.
Бакалына салып хәмер эчтем,
Тәмәкесен аның көйрәттем.

Гомер буе гел яхшылык эзлим,
Башка юлны эзләү мәгънәсез.
Кемлегемне сезгә күрсәтергә,
Дәрәҗәле урын бирмисез.

Юашландым, тайфукландым белеп,
Күп тапкырлар әйттем тәүбәсен.
Усал телләр гайбәтемне сатты,
Теләгәнчә әйдә сөйләсен.

Миндә күктән, җиргә төшмәгәнмен,
Булды юлдан язган чакларым.
Намусыма кара тап төшермим,
Кыйбылама табан атладым.

Тар сукмактан олы юлга бастым,
Тормыш таныгачтан күз ачтым.
Ваклык белән артык мавыкканмын,
Андый сабыйлыктан мин качтым.

Дөнья усаллыгын да күрсәтте,
Теләгәнчә бирде кирәкне.
Акыл биреп, сабак биреп торды,
Ничек яшәргә ул өйрәтте.

## Син язмышым

Тормыш юлым илтә киләчәккә,
Язмышымның белмим кайсысы.
Кемнеңдер син бетмәс зур шатлыгы,
Кемнеңдер син ачы кайгысы.

Мин киләсен син дә белмәгәнсең,
Юлларымда сине очраттым.
Күрер күзләремә нур балкыттың,
Бер күрсәм дә инде охшаттым.

Күзләребез сүнмәс ялкынланды,
Сүзләребез сүзгә кушыла.
Көтмәгәндә кызык булды бу хәл,
Килеп бастың көлеп каршыма.

Без моңарчы таныш булмасакта,
Күңел тартылгачтан караштык.
Күпме күзләр арасыннан сайлап,
Якын күреп, көлеп табыштык.

Киләчәккә барам юлларымнан,
Син язмышым, белмим кайсысы.
Кемнеңдер син бетмәс зур шатлыгы,
Кемнеңдер син бетмәс кайгысы.

* * *

## Бер карашың җитә

Юк, сизмисең ахры карашымны,
Сиңа гына туктап күз кысам.
Тоярсыңмы икән йөрәгемне,
Аңлатырга теләп сүз кушам.

Керфегеңне сирпеп тарсынмыйча,
Каршыма ук килеп бас әле.
Челтәр пәрдәләрен күтәреп куй,
Тәрәзәңне иркәм ач әле.

Бер карашың җитә,
Башка берни теләмимен.
Елмаймыйсың, нигә көлмисең.
Ялкынланды кайнар хисләрем,
Их, син генә аны белмисең.

Мин чакыргач, син дә килерсең,
Якын күрсәң, әгәр иш итсәң.
Мин бәхетлемен дип әйтермен,
Сөям, дигән сүзең ишетсәм.

* * *

# Якты таңнар көтәсең

Әни, кызлар кебек,
Мич буена утырып
Чәч толымнарыңны сүтәсең.
Уйчанланган якты карашларың,
Күңелең белән кемне көтәсең.

Улларыңны сөеп үстерден дә,
Буйга җиткәч,
Төрле якка китте таралып.
Басып калдың
Йортың уртасында,
Бер ялгызың гына каранып.

Көннәр сиңа
Ел шикелле озын,
Акрын үтә вакыт көткәнгә.
Аерылышу, очрашу белән,
Гомер юлың синең чикләнә.

Кышка керсәң,
Кайтмас, буран, дисең,
Карлы юлга шомлы карыйсың.
Күрешү көнен көтәсеңдер,
Минутларын аның саныйсың.

Җәйләр җитсә, яшен яшьни,
Матур көннәр сиңа аз сыман.
Бәйләүләрдә торган ат шикелле,
Тынычланмыйсың ич син һаман.

Аткан таңнар куанычлар бирә,
Һәрчак көтеп каршы аласың.
Каршыладың якты көннәреңне,
Моңсуланып озатып каласың.

# Мәхәббәтем гомерлек

Яраларым тирән төзәлмәстә,
Ах, йөрәгем әрнеп сикерә.
Телең белән сөйләп аңлатмыйсың,
Карашың да сине җиткерә.

Су юлыннан кайтсаң карап калам,
Иңнәреңдә тулы чиләгең.
Сүз кушсам да, туктап сер бирмисең,
Башым иям түбән, чибәрем.

Яшьлегемнең ямьле язындамын,
Куанычта көтәм көч кенә.
Уртак итәр идек язмышларны,
Аңлаталмыйм сиңа һич кенә.

Горур җаның хисләр ургый синең,
Бер төрле уй килмәс башыңа.
Ашкынмыйсың, ярсымыйсың әле,
Синең җырны көйли барсыда.

Хыялларың бәхет вәгъдә итә,
Тоемлыйсың алдан белерлек.
Яшьлек уза, еллар алып китә,
Мәхәббәтем кала гомерлек.

* * *

# Игенче басу түрендә

Төне буе карлар ява сибеп,
Ак юрганга төренеп җир ята.
Таң яктысы әле төшмәс борын,
Игенчене уйлар уята.

Иртән торса басуларга чыга,
Кар катламын үлчи, актара.
Яшел уҗым кыякларын күреп,
Шатлыгыннан йөзе яктыра.

Ачы җилдә, салкын бураннарда,
Чыгып карый уҗым өсләрен.
Туң балчыгын алып иснәп карый,
Тоя әллә икмәк исләрен.

Бер офыктан, бер офыкка карый,
Бар тарафта басу киңлеге.
Теләкләре генә чыңга ашсын,
Ачыкланыр аның кемлеге.

Дөнья мәшәкатен читкә ташлап,
Ничә уза басу түренә.
Хыялында тук башаклар шаулый,
Офык читләрендә күренә.

* * *

# Очрашкан мизгелләр

Урам буйлап атлап килгән чакта,
Кыюлыгым җитем эндәштем.
Биек кыяларга очып кунган,
Бөркетләргә шулчак тиңләштем.

Нурлы карашларың исерттеме,
Уйларыма чәчең урала.
Төрле якка уза юллар очы,
Ике тормыш ята арада.

Синең яннан тыныч узалмадым,
Ярсу хисләр миндә кузгалды.
Мөлаемле, иңле булып үсә,
Назландыра авыл кызлары.

Бер карашың белән туктаттың син,
Узган чакта урам чатыннан.
Үз вакытын белеп очраштыра,
Язмыш үзе безне чакырган.

* * *

# Гомерләр

Еллар саны,
Әллә узган юллар,
Гомер озынлыгын билгеле.
Безнең гомер киләчәккә таба,
Серле йомгак төсле тәгәри.

Гомер юлы, гомер озынлыгы,
Кешеләргә тигез тимәгән.
Күпләр калды көрәш кырларында,
Җаны каны белән түләгән.

Салаватлар, Мусаларың биек
Күтәрелде илем күгенә.
Күктә янган йолдызларның берсе,
Нурлар түгеп җиргә түгелә.

Җиңү юлын безгә кисәтәме,
Язлар җитсә ярсый ташкыннар.
Мәйдан уртасында һәйкәлләр бар,
Каһарманнар менеп басканнар.

Көрәш юлын һәйкәл үзе сөйли,
Нур балкышы аннан тарала.
Батырларның гомере мәңгелек,
Тере булып яши арада.

Ихтирамга, данга килү юлы,
Беркем әйтмәс аны күп төрле.
Үлчәүләргә салып бәһаләнми,
Кеше гомерләре кадерле.

✳ ✳ ✳

***

Очрашканда безнең сүзләр бетми,
Алларыма үзең төшәсең.
Яннарымнан китеп күз качырасың,
Үтмәс пычак белән кисәсең.

***

Үзем йорт төзим хәзер дип,
Сөйлисең телең белән.
Күргәнем юк какканыңны
Кадакта кулың белән.

***

Мөдир булып алгач инде,
Сөйләшми кеше белән.
Имеш ул дөнья кендеге,
Мәшгуль үз эше белән.

***

Тәмәкесен ташларга,
Көтә генә ул җаен.
Тартуны ташладым, ди
Акчасы беткән саен.

# Каен бөреләре ачыла

Күк өстендә янган йолдызларга,
Горур башын таулар күтәрде.
Дарьяларда шаулый кар сулары,
Яз шатлыгын җиргә китерде.

Табигатьнең төрле мизгеле бар,
Кырыслыгын ахры яшерә.
Ярсып аккан көчле ташкыннарның,
Тавышлары ерак ишетелә.

Куанычым, сөенечем арта,
Уртак булсын газиз дусларым.
Илләр буйлап килгән тантанага,
Канат кага сайрар кошларың.

Җир бизәлә, сокландыра тагын,
Ямьле, назлы хуш ис чәчәкле.
Мәңге бетмәс аның гүзәллеге,
Җир бизәге төрле шул чаклы.

Дулкыннарны куып дулкын кага,
Көч хәрәкәт таба тамчыда.
Биләүләрдә яткан бала төсле,
Каен бөреләре ачыла.

* * *

# Ир булырга кирәк

Бу дөньяда
Бер без генә микән.
Юк барга да кәеф кырыла.
Циклоннар күтәрелә канда,
Давыл чыга йөрәк кырына.

Диңгез төсле салкын сулыш өрә,
Бозлар кага күкрәк челтәрен.
Җәйрәп яткан гомер сукмагыма,
Җил түшәде тормыш чүпләрен.

Вакланмаска, борчылмаска юкка,
Ничә тапкыр куйдым күп нокта.
Сабырлыгым, ихтыярым көче,
Җитмәс төсле, никтер куркыта.

Ир булырга белергә дә кирәк,
Югалтамын кайчак саклыкны.
Кичермәгән булсам кайгыларны,
Тоймас идем бәлки шатлыкны.

Ир башыннан үтә барсыда,
Үлем көтә, давыл кичерә.
Тау кадәре килә кайгы-хәсрәт,
Үзе татый бөтен көченә.

Аңлаталмыйм шундый мәлләр була,
Сизмичә дә керәм вак счетка.
Ир булырга ихтыяр-көч тапсам,
Ирешермен миндә максатка.

# Тыныч булсын дөньялар

Ачы искән җил ягына карыйм,
Кайсы океан давыл күтәрә.
Иртән торсам
Мин Мәскәүне тыңлыйм,
Нинди хәбәр илгә китерә.

Ике дөнья,
Ике язмыш җирдә,
Туплар тора әле шартларга,
Күз карасы кебек кыйммәт безгә,
Тынычлыкны кирәк сакларга.

Кем хаклы соң
Гөл бакчалы илне
Утка тотып күмер итергә.
Еллар шаһит
Үткән язмыш тарих каршында,
Сабак түгел нигә күпләргә
Кайгыларга юлыкмасак икән
Афәтләрдән җаным өшегән.

Илем хаклы,
Үз җилкәсендә күп
Хәсрәт давылларын кичергән.
Гөлләр үсә, җирдә чәчәк ата,
Җырын көйләп ага дарьялар.
Якты көннәр шатлык белән килә,
Тыныч булсын иде дөньялар.

***

Зәңгәр күлдә үскән төнбоекта,
Яктылыкка көнгә ачыла.
Кош баласы кадәр генә йөрәк,
Талпына да үзе ачына.

Ихтирамга, назга баш иям гел,
Борчуларга йөрәк ярсыма.
Нинди генә биек тау булса да,
Канат җәеп килә каршыма.

Тормыш кочагына алып сөйми,
Уй-фикерләр арта башыма.
Сабырлыгым җитә, мәхәббәтем әнә,
Бөреләре яңа ачыла.

# Бер син генә түгел

Бу дөньяда бер син генә түгел,
Бер син генә күктән төшмәгән.
Син түгелсең ташка җан өрүче,
Күк йөзеннән йолдыз чүпләгән.

Кыланышың, ашкынуың хәтәр,
Ничек чыгалырсың чигенә.
Өч йөз алтмыш градуска борган,
Җир кендегеме соң син генә.

Яшен суккан имән агачы күк,
Урын тапмый кинәт чатныйсың.
Тау кадәре ихтирамын күргән,
Дусларыңны читләп атлыйсың.

Иптәшләрең сиңа зур аяныч,
Артык шашма, артык кабынма.
Кеше кызык, сизмичәдә кала,
Атлап барган юлда абына.

Йөргән юлларыбыз уртак булды,
Чишмә безгә суын эчерде.
Дуслык хисе берүк сүрелмәсен,
Күңел йөгерек авыр кичерде.

* * *

# Юлдаш итәм әни үгетен

Истә тотам әби әкиятен,
Онытмадым әни үгетен.
Тәрәзәгә таш ыргыткан малай,
Буйга үсеп җиткән егетмен.

Шаянлыгым булды яшермим,
Каргаганнар, тетеп сүккәннәр.
Син сөйләгән, әби, әкиятләр,
Барысы да баштан үткәннәр.

Гаҗәп гомер серле йомгак кебек,
Кызык кына үзе сүтелә.
Белми калдым, хәтта сизмәдемдә,
Барып җиттем дөнья читенә.

Язмышыңа хуҗа булалмыйсың,
Кая илтмәс адәм баласын.
Олы бәхет тормыш вәгъдә итеп,
Күп ашатты нужда калачын.

Мәрхәмәтсез, кырыс еллары да,
Көткән вакыт күпкә соңлады.
Үз ирләрен Ватан төрле чакта,
Айлап түгел, еллап сынады.

Көнгә керсәм кырык төрле булам,
Әкияттәге батыр егетмен.
Әллә кайчан юлдан язар идем,
Юлдаш иттем әни үгетен.

# Дусларым үз итә

Мин караны һәрчак кара дидем,
Акны әйттем барыбер ак ул дип.
Охшамады
Кайбер абзыйларга,
Бармак яный,
Энем, сак бул, дип.
Нишләргә соң,
Телем бармады шул,
Бутамадым акны карага.
Барыбызга да уртак булган,
Дуслык хисен тапмыйм арада.
Хаклык икән,
Алар шикләнәләр,
Яратмыйлар аны, сөймиләр.
Нинди гамьсезлек бу,
Юл чатында җыйнаулашып,
Яман атны бары сөйлиләр.
Ящермимен
Төрле чаклар булды,
Юк бар өчен көйрәп җан аттым.
Чибәр кызлар күрсәм гашыйк итте,
Матур хатыннарны яраттым.
Гайбәтчеләр шуңа гайбәт сата,
Түрәләрем каты шелтәли.
Нахак белән хакны аералар,
Җан дусларым мине читләми.

## Төрле кичерешләр

Адашканда юллар очын эзлим,
Сусаганда сулар тапмадым.
Хаталансам кылган эшләремә,
Авыр сулап ахры акландым.

Аты ташлап качкан егет сыман,
Мөшкел уйлар күңел кичерә.
Салкыннарда җылы табалмадым,
Калтыранам, тәнем күшегә.

Мохтаҗлыкта, тоткын хәлендәмен
Ычкынырга җаен эзләдем.
Мондый хәлдә җаным тынычланмый,
Сыкрандың йөрәк түзмәдең.

Мин иреккә хәят киңлегенә,
Кулларымны сузып үрелдем.
Ничә тапкыр икән яраландым,
Ничә тапкыр икән терелдем.

Көн туды исә мәшәкатем арта,
Борчулардан читтә калмадым.
Баштан уза төрле кичерешләр,
Яшәү кызык шуны аңладым.

# Нинди заманага калдык

Нинди заманага калдык икән,
Соңгы штанныда салдыра.
Безне алдыйлар да, талыйлар да,
Адәм көлкесенә калдыра.

Күп түрәләр вәгъдә итә оҗмах,
Чынга ашмый теләк, буш калдык.
Юлдан яздык, тәмам адаштык бит,
Ялган фәлсәфәгә ышандык.

Каракларга җае килеп тора,
Фәхишәләр хәзер шәпләнә.
Дустан, дошманыңны аермыйсың,
Туганыннан кеше шикләнә.

Каргыш, рәнҗеш, гауга илдә бетми,
Касталарга халык бүленә.
Тормыш газабына ничек чыдый,
Тал чыбыгы сыман бөгелә.

Әфәнделәр нәфселәшкән чакта,
Күк күкери, яшен яшнәтә.
Ашарына икмәк җиткерәлми,
Арык хәлдә яши эшләптә.

Безне язмыш төрле якка чөйде,
Яфрак кебек калдык эленеп.
Тулгак тоткан хатын хәлендәбез,
Сулыш җитми, кала бүленеп.

# Яфраклар серләшә

Агачлар өнен ишетәм,
Яфраклар да серләшә.
Егетләр, кызлар шикелле,
Бергә алар сөйләшә.

Аяз көндә тыныч кына,
Яфраклар да шәпләнә.
Кояшка бора йөзләрен,
Шау-гөр килә, шатлана.

Әз генә җилләр иссә дә,
Яфраклар да шомлана.
Әйтерсең дога укыйлар,
Үзләренчә моңлана.

Күкрәү уза күк өстеннән,
Яшен уты ялтырый.
Тауны, ташны сискәндерә,
Агач, яфрак калтырый.

Яфрак белән яфрак сердәш,
Сорашамы хәлләрен.
Ишетергә иминлеген,
Тели дөнья хәбәрен.

* * *

# Болыннарда чәчкә исе

Болын буйларында атлар кешни,
Каңгылдаша казлар төркеме.
Җанга тансык, рәхәтлеген бирեп,
Үләннәрдән хуш ис бөркелде.

Якын гына инеш агып ята,
Үз телендә көйләп җыр суза.
Тугайларга, үзәннәргә табан,
Һәр тарафка моннан юл уза.

Җаным сихырланды болын синдә,
Күкләреңә мине күтәрдең.
Чәчкә - гөлләр арасында йөреп,
Озын көннәремне үткәрдем.

Тугайларда җир җиләге пешкән,
Үзәннәрдә шаулый тирәгем.
Җәйләр җитсә, сәхрә кочагына,
Әйдәләде мине йөрәгем.

Болын хозурлыгын күреп туймый,
Күбәләкләр оча тирәмдә.
Шук малайлар кебек, җиргә ятып,
Бер аунасым килә чирәмдә.

* * *

## Йөрәк сагышы

Йөрәкне сагыш алды,
Сүнми дә, сүрелми дә.
Күрәп яткан учак төсле,
Ялкыны күренми дә.

Күңел җәрәхәте бетми,
Йобанырга юк чара.
Җил истеме, таллар да бит,
Башларын җиргә ора.

Таллар булып бөгеләмен,
Югалтуга тарыдым.
Шау - шу алып килә көннәр,
Борчуларга арыдым.

Кайчак ярсыйм тулпар кебек,
Ашкынам җаным түзми.
Дөньяның кайсы җирендә,
Бушаныр урын эзлим.

Авыр кичерешләрдән соң,
Мин калам исән - тере.
Сагышымны юып ала,
Сандугач, былбыл теле.

* * *

# Киләчәк көн билгесез

Дөньяларның асты-өскә килде,
Рәхмәт бетте, шәфкать калмады.
Нәфселәшә һаман намуссызлар,
Байлык җыя, илне талады.

Эшсезлек һәм фәхишәлек арта,
Ялган акча йөри ил буйлап.
Бер хуҗасыз калган йорт шикелле,
Ил хәстәрен күрә кем уйлап.

Анархия хөкем сөргән заман,
Кемнең кем икәнен белмәссең.
Башбаштаклык, төрле афәт туа,
Мондый хәлгә йөрәк күнмәссең.

Халык дәшми, аптыраган хәлдә,
Күреп тора, барын күзәтә.
Горурлыгы, сабырлыгы җитә,
Үрелмәде олы күсәккә.

Әфәнделәр халык белән уйный,
Белмим тагын нәрсә китерер.
Кабатлансамы 17 нче ел.
Йөзегезгә халык төкерер,
Киләчәк көн нәрсә китерер.

* * *

# Вакытлар үтә

Көнем кичкә авыша бара,
Сары яфраклар ауный.
Вакытлар йөгереп үтә,
Йөрәгем моны аңлый.

Күктә торналар төркеме,
Хушлаша сәлам биреп.
Җаным бары өзгәләнә,
Барысын күреп, белеп.

Юллар урау адашырлык,
Болытлар яшен түкте.
Ике яшәргә килмәдем,
Өмет итмәдем күпне.

Гаҗәпләнмим аккан суга,
Гомерләрне кисәтә,
Еллар, айлар узган саен,
Алам барын исәпкә.

Йөз яшәргә дәгъвә итмим,
Җирдә яшәве чикле.
Яшерен хазина кебек,
Серләрен ачмый, бикле.

* * *

# Таңны көтәм

Офыкта таң уянмаган әле,
Сайрар кошлар какмый канатын.
Төн пәрдәсен япкан җир өстенә,
Бар табигать йоклый, тора тын.

Анам кебек җирем сак йоклыйсың,
Яфрак пышылдаса, сискәнә.
Галәм киңлекләре серен ачмый,
Җил иссә дә кинәт шикләнә.

Тау астында көмеш чишмәләрем,
Җырын сузып көнне каршы ала.
Таң сызылып ата, күгем аяз,
Илем имин тора иншалла.

Бал кортлары очар иртә белән,
Җирем чәчәкләре елмаер.
Шаулаганда иген басулары,
Шатлык тоеп күңел юаныр.

Алсу таңны көтеп аттырамын,
Төн карасы җирдә эресен.
Нинди булыр инде, килер көнем,
Йокым килми, уйлыйм төрлесен.

* * *

## Такыялар үрәм

Җәй көнендә болыннарга чыгам,
Миңа тансык аның сукмагы.
Яшел үләннәрдә җемелдәшә,
Иртә-кичен көмеш чыклары.

Төрле моң - авазлар ишетелә,
Назландырып хисләр уята.
Яшьлегемә кайтам, сафлык, пакьлек,
Көчем, дәртем арта унлата.

Болын кочагында тулпар булам,
Күбәләкләр булып очамын.
Күзләремне сөеп камаштырган,
Гүзәл дөньям, ишек ачамын.

Мәңгелекнең бер мизгелен күрәм,
Ышанырлык аның көченә.
Ямнәреңне йомарт өләшәсең,
И, табигать, барын кешегә.

Сукмакларым алга дәшеп тора,
Офыклары якты күрәмен.
Асыл гөлләр җыям учларыма,
Такыялар җырлап үрәм мин.

* * *

* * *

***

Авылыма кайттым исә,
Болыннардан урыймын.
Сабырлык бир җаныма дип,
Туган җирдән сорыймын.

Печәннәр чапкан җиремсең,
Атлар саклаган урын.
Чаралар юк юксынуга,
Сагынып кайтам барын.

Балтырган,какы, кузгалак,
Мин җыям учларыма.
Утлар тергезеп җибәрәм,
Дөрләсен учагымда.

Җир җылысын, йомартлыгын,
Тоям аның хуш исен.
Йөрегән сукмакларыма,
Гөл-чәчкәләр түшисең.

Чит якларда гомер үтә,
Кайталмыйча кичектем.
Тургайларым исән әле,
Мин җырларын ишеттем.

# Ходай, сабырлык бир

Кешеләргә сабырлык бир ходай,
Ах-зарлы, мохтаҗлы да бүген.
Сагышлары сары болыт булып,
Томаладымы аяз күген.

Әле анда, әле монда һаман,
Туплар шартлау тавышы тынмады.
Егерменче гасыр син, шаһитсың,
Кулны кыскан богау чыңлады.

Кеше язмышлары төрле була,
Үз бәхетен һәркем юллады.
Билгесез шул иртәгәсе көне,
Ышанычлар эзләп юанды.

Адаштыра тормыш сукмаклары,
Оран сала кеше галәмгә.
Заман җилләре дә каршы исә,
Язмыш сыный шулай гамәлдә.

Җан өшеткән хәлләр туып тора,
Авыр йөкләр ята иңемә.
Иминлеге булсын, иман кайтсын,
Хөрмәт артсын инде илемә.

* * *

# Үткәнемә карыйм

Күңел күзем үткәннәргә карый,
Хәтеремнән берни юмадым.
Күргән төш шикелле генә калды,
Барысын да кабат юлладым.

Бер хисләнеп, бер бушанып алам,
Әйтерсеңлә дарья буйладым.
Шаулап узган яшьлек елларына,
Алып кайтты татлы уйларым.

Җиһан кораблары очып җитмәс,
Ерак калган ямьле көннәрем.
Үткәннәрдән урап кайтучыны,
Бу дөньяда әле күрмәдем.

Хыялларым үткәннәргә итә,
Күпер салып, юллар төзимен.
Сагынуларга дәва табалмадым,
Сабырлыгым җитсен, түзәрмен.

* * *

# Җәйнең ямен алып киттең

Җәйләремнең ямен алып киттең,
Җылы җитми, җаным өшеттең.
Аерылуга, югалтуга чара,
Табалмадым ахры кичектем.

Төнге йокымнанда мәхрүм иттең,
Керфек очларында күз яшем.
Җир тетри, күк чайкала сыман,
Утлар йотып инде мин яшим.

Аерыла да, кавыша да кеше,
И, йөрәгем, син дә күнәрсең.
Тетрәнәмен, сыкранамын ялгыз,
Язмышымдыр ахры, күрәсең.

Пар аккошлар күл өстендә оча,
Күзләремне карыйм талдырып.
Үкенечле хәл тормыш юлдашым,
Ташлап китте ялгыз калдырып.

Адаштырды, тормыш юлларыбыз,
Ачыклыймын аның сәбәбен.
Бик күрәсем килгән чакларым бар,
Җилләр әйтер сагыну сәләмен.

* * *

# Ихлас булу кирәк

Дусларымның да ихласлыгы җитми,
Тоймыйм кайчак якты карашын.
Үлчәүләргә салып булса икән,
Йөрәк белән йөрәк арасын.

Бер ваемсыз кош баласы кебек,
Көтәм әле канат кагасын.
Бу дөньяга ходай яраткан шул,
Төрле итеп адәм баласын.

Бер үк кояш көлә күк өстендә,
Җир тирбәтә яшел бишектә.
Горур йөртик җанда дуслык хисен,
Мөшкел хәлгә калмыйк ничек тә.

Песигә дә ишек ачып торам,
Кылган эшең булсын саваплы.
Адым саен, минут саен кеше,
Үзен тойсын иде җаваплы.

* * *

# Яшьлегем тугаенда

Ат саклаган, печән чапкан,
Җиләк җыйган җиремсең.
Яшьлегем яшел тугае,
Җырлап туймас җырым син.

Йолдызлар кебек җемелдәм,
Үләннәрдә чык балкый.
Җанга рәхәт, ләззәтләнәм,
Чәчкә исләре аңкый.

Эзләрем калган тугайда,
Сукмакларың саклаган.
Кошларның дәртле моңына,
Малайлар күк сокланам.

Яшелеккә төренгән җир,
Сафлыгына табынам.
Урау юллар үтеп килдем,
Сагыш хисе кагылган.

Күз алладым үткәннәрне,
Табигать кочагында.
Дөрләсен, утлар кабызам,
Күңелем учагына.

* * *

## Мин дә хушлашырмын

Күз йомылыр бер мәл мәңгелеккә,
Гәүдәм талыр тирән йокыга.
Өнсез генә хушлашырмын шул чак,
Ятимлеген тояр йортымда.

Сакат тавы уйчанланып калыр,
Чишмәләрем моңсу җыр көйләр.
Өй артында үскән каеннарым,
Минем хакта белмим ни сөйләр.

Искән җилме, аккан сумы булды,
Сизелмәде гомер узганы.
Түгелеп тә, сибелеп тә калды,
Әйтерсеңлә юллар тузаны.

Кешеләрне җыя җир куйнына,
Исәпләшми ничек бу хәтле.
Йөз яшәгән адәм балалары,
Язмышлары белән бәхетле.

Йөрәк күнми, ышанасы килми,
Тере калырмын күк ничек тә.
Вакытларны кичектереп булмый,
Үлем килер бер көн ишеккә.

* * *

# Җаным җәрәхәтле

Күп сөйләүләр фәтүәсез булды,
Сизеп, күреп барын күзәттек.
Әвәлгедән калган ак тапларны,
Хаталарны имеш төзәттек.

Без йомышчы малай кебек кенә,
Йөгереп йөрдек тормыш юлында.
Кайсы якка дөнья үзгәрә соң,
Ил корабы кемнәр кулында.

Бер сүгәсе, сүгенәсе килә,
Шулмы яшәү, җәфа чигәбез.
Кафтау арты булсын шикләнмичә,
Бәхет эзләп сәфәр чыгабыз.

Кара җирдә чана сөйрәп үстек,
Әрәм узган гомер тик бушка.
Менеп булса җиденче кат күккә,
Калмас идем монда мин башка.

Кул сузалар кеше бәхәтенә,
Ләззәт ала, кемнәр тәм таба.
Җанда төзәлмәслек җәрәхәт бар,
Керфек очларыннан яшь тама.

* * *

# Рәсәй

Газиз җирем, туган илем димен,
Бер горурлык белән атладым.
Мохтаҗлыкта нишләп яшәтәсең,
Син Рәсәй, минем Ватаным.

Мәңге гауга, талаш илдә бетми,
Кан яшьләргә тулган җир өсте.
Тыныч тормыш, хезмәт сөйгән халык,
Теләгенә кайчан иреште?

Дәгъвәләшеп көч күрсәтеп һәрчак,
Сугыш белән керден күршеңә.
Вәхиш җаннар хөкем иткән илдә,
Кадер-хөрмәт калмый кешегә.

Кара болыт булып ах-зарыбыз,
Күтәрелгән илем күгенә.
Мөшкел хәлгә калган фәкыйрлектә,
Кеше карашыннан күренә.

Эт тормышы, сукбай хәлендә бит,
Богау кыса аяк-кулларын.
Кыргый закон хөкемнәре белән,
Үз халкың бит, Рәсәй, колладың.

Офыкларны баскан сары сөрем,
Кай яклардан килеп сыена.
Миллион кешеләрнең түккән яше,
Каһәр тигән җирең - суына.

## Чибәркәем

Чибәрлегеңә масайма,
Сылуларны мин күргән.
Төрлесен сөйдем саташып,
Хәтта төшләрдә күрәм.

Синең күзләр дә бик шаян,
Мут булырга охшыйсың.
Ирләр затын чит күрмисең,
Утлы караш ташлыйсың.

Син фәрештә түгелсең лә,
Күктән төшмәгәнсең лә.
Гомер язың ашкындыра,
Бер чак хисләр дә сүнә.

Чибәрләргә кем табынмас,
Мин оялып сүз кушам.
Кыюсыз малай кебекмен,
Югалып калам кайчан.

Җилкенмәсен, шашынмасын,
Күңел бер үк азмасын.
Азып-тузып йөрүчеләр,
Илдә әллә азмы соң.

Сылукаем, син баскансың,
Кайсы юл чатлыгына.
Төрле хәлгә юлыгырсың,
Татырсың шатлыгын да.

## Яшел ялкын сүнә

Өй алдында тополь агачлары,
Яфраклары җиргә сибелгән.
Көннәр моңсу, җылы җитми төсле,
Кояш кайнарлыгы сүрелгән.

Чәчкә - гөлләр башын чайкый,
Искән җилдә тирбәлә.
Тирә-юньгә аваз салып,
Яфрак-үлән телләнә.

Күктә казлар каңгылдаша,
Юл яра канатлары.
Елның бу мизгеле ничә
Гомергә кабатланды.

Яшел ялкын җирдә сүнә,
Күк чатырларын җыйган.
Табигать хөкеме белән,
Ямьле җәй төсен җуйган.

✳ ✳ ✳

***

Яшьли тарттык тәмәке дә,
Шәрабында эчтек без.
Сука сөреп, көтү көтеп,
Авыл синдә үстек без.

Яр буена учак яктык,
Кармак салдык инешкә.
Табышыбыз мулдан булып,
Чыкты безнең өлешкә.

Кызык та, мәзәк тә күрдек,
Җитез йөгердек илдән.
Ачлык та күреп яшәдек,
Башак та җыйдык җирдән.

Безне күреп этләр өрде,
Ата казлар талады.
Шук малайлар дигән исем,
Авыл буйлап таралды.

## Усаллык бар

Усаллыкта, дуамаллыкта,
Канга сеңгән җитәрлек.
Хөсетлек кылып, үч алып,
Кайчак бокал күтәрдек.

Гамьсезлеккә күнеккәчтен,
Тамырын корытмадык.
Намус, әдәп сакламадык,
Беркемнән курыкмадык.

Тәккәберлек дә кешенең,
Җанына оя кора.
Әйтерсеңлә җир кендеген,
Кулында тотып тора.

Нәфсе колына әйләндек,
Диңгезгә тиңдер чиге.
Хафага салып тора гел,
Күп төрле кеше чире.

Сабыр итми, шөкер итми,
Вакыт узганын сизми.
Кыска гына гомерендә,
Афәтен кеше эзли.

* * *

## Теләкләрем аклансын

Болыт булып килде кайгыларым,
Баш өстендә яшен яшьнәттең.
Үгиләттең, тормыш, мине һәрчак,
Җәбер күрсәтеп гел яшәттең.

Гел өстәлеп тора кайгыларым,
Күз яшьләрем белән түләдем.
Ходай бирсен сабырлыклар бары,
Ихлас күңелемнән теләдем.

Авызыма капкан ризык бармый,
Урынымда тапмыйм йокымны.
Төнгә керсәм шомландырып кына,
Күктә көлгән аем тотылды.

Адаштыра юл йөрергә чыксам,
Йөз тотамын кыйбыла ягына.
Мин бер мосафирдай күпне күргән,
Карасын да дөнья агын да.

Аягыма басам бар көчемә,
Изге теләкләрем аклансын.
Гомер сукмагында ниләр булмас,
Кайгы җиле бәреп екмасын.

* * *

# Кем тормыш җаен белә

Күпләр бүген йорт сала
Агачтан, таштан өеп.
Икешәр, өчәр катлы,
Күккә үрелә биек.

Акчасыз заманда,
Ничек җаен табалар.
Төрле хикмәт кылып яши,
Нәфселәнә түрәләр.

Законы-хөкеме дә бит,
Үзгәрде, хәзер башка.
Илем, халкым җилкәсендә,
Йортлар төзиләр бушка.

Капкасы да тимердән шул,
Җил дә керәлми үтеп.
Миңа да бер бәхет кошы,
Кунмасмы яшим көтеп.

Кемгә алтын йомыркасын,
Сала көндә тавыгы.
Берәүгә җирдә оҗмахта,
Берәүгә җир тамугы.

* * *

# Шик астына куя

Шик астына куя билгесезлек,
Соры болыт баскан ил күген.
Болганчык су кебек сәяси хәл,
Аңлый алмыйм хәзер мин күбен.

Спекулянт чәчкә аткан заман,
Фәхишәлек арта дөньяга.
Ил байлыгын талап күп түрәләр,
Мая сала әзер ояга.

Халык дәшми, давыл көтә сыман,
Бер чыгарыр соңгы карарын.
Зур ышаныч белән кешеләргә,
Күз яшьләрем аша карадым.

Заманасы чуар, үзгәручән,
Арзан баһалана намуста.
Аферистлар дан-дәрәҗә юллый,
Файдаланып кала бик оста.

Ил эчендә ызгыш, талаш бетми,
Бер-берсеннән кеше шикләнә.
Нинди дәвер капкасына кердек,
Үз-үзенә күпләр бикләнә,
Йөрәк чуар, күңел чүпләнә.

* * *

# Әти сука сөргән җир

Әти печән чапкан тугай,
Әни су алган чишмә.
Алар йөргән сукмак буйлап,
Көнгә урыймын ничә.

Юксынуым, сагынуларым,
Күңелгә сала яра.
Юллар тапмыйм үткәннәргә,
Өзелгән барыр ара.

Югалтулар үкенечле,
Кисәтә иртә-кичен.
Ходай сабырлыклар бирсен,
Җитсен ихтыяр көчем.

Басуга чыгып юанам,
Игеннәр шаулый - уңган.
Әти сукалаган җирне
Әни урагын урган.

Җир хәтере җуелмаган,
Җил тарата моң-зарын.
Кырларда юксына икән,
Башаклар көйли җырын.

* * *

## Дулкыннар дулый

Бишегендә яткан бала төсле,
Дулкын өсләрендә тирбәләм.
Колачларын җәеп акчарлаклар,
Очып үтте минем тирәмнән.

Ярсый дулкын аргамаклар кебек,
Ярларына сыймый дулады.
Кыя ташларына башын салып,
Көчсезлеген сизеп улады.

Иркенлекне, чиксезлекне тели,
Дулкын ярларыннан чыгарга.
Бар көченә үзе шашынса да,
Туры килеп бетми чамага.

Су төбенә төшкән кебек була,
Күз алдында дулкын йотыла.
Яр буйларын тынлык биләп ала,
Әйтерсең лә тала йокыга.

Дулкын гомере дә мизгел генә,
Яшен ташы сыман тиз сүнә.
Үз хәленә кайтып төшенәдер,
Ярларына туктап тез чүгә.

* * *

# Әрне-хурны белмисең

Оялмыйсың, әрсез җан син,
Әрне-хурны белмисең.
Уйланмыйсың, кимсенмисең,
Ни кылсаң да өнисең.

Горурлык хисе тоймыйсың,
Түбәнлек бу, мескенлек.
Ничек гамьсез яшәргә соң,
Дөнья алдый өч көнлек.

Очсызланма, вакланма да,
Кадереңне югалтып.
Ямьсез кыланышыңны һич,
Кабул итмим яратып.

Бик тә сәер күренәсең,
Чама барын белмисең.
Маймыл кебек кыланасың,
Үзеңнән ник көлмисең,
Юк, тәүбәңә килмисең.

***

Гомер буе сүз ишеттем,
Юаш син пешмәгәнсең.
Сабак алмыйсың һаман да,
Терсәкне тешләмәссең.

Ятлар әйтә шулай кирәк,
Дуслар акыл өйрәтә.
Тоз сала йөрәк ярама,
Ут-ялкыны көйрәтә.

Усал булмагач анамнан,
Яңадан туаргамы.
Кеше җанына тияргә,
Тиресен тунаргамы?

Булдыксызга да саныйлар,
Гамсезлеккә тиңлиләр.
Ата-анамны куймыйлар,
Сүгеп, тетеп тиргиләр.

Кешене кыерсытмадым,
Усал булып үсмәдем.
Эт шикелле өрмәсәм дә,
Кан чыгарып тешләдем.

## Вакыт җитми

Табыннарда пешкән ашлар көтте,
Җәйгән урын калды, ятмадык.
Очрашырга сүз куешкан идек,
Күрешергә вакыт тапмадык.

Иртән торсаң дөнья мәшәкате,
Ялкын булып дөрли канымда.
Кырык җирдә кырык эшем көтә,
Эш карышмый минем кулымда.

Яшәү ямен, тормыш матурлыгын,
Үз күзләрең белән күрәсең.
Гөл бакчасы итәм җир өсләрен,
Бил бөгелсен, тирем түгелсен.

Минутыда алтын кебек кыйммәт,
Бушка узмасын дип кайгырам.
Язмыш әллә шулай кушты микән,
Бәхет ишекләрен каерам.

Ир уртасы булып өлгерсәм дә,
Нәрсә генә әле эшләнгән.
Хезмәт җимешемнең бар булганы,
Тормыш бизмәнендә үлчәнгән.

Сүнгән утым әле кабынмаган,
Сибелмәгән җиргә суларым.
Мәхәббәтем күптән бөреләнгән,
Өйләнергә ахры соңладым.

Күңел түрендәге изге теләк,
Илтә мине якты бер хискә.
Тау кадәрле күпме эшләр көтә,
Вакыт җитми, куллар бик кыска.

# Кич утырган кызлар

Төннәр буе кызлар кич утырган,
Җеп эрләгән, чигү чикәннәр.
Кич утырган йортның тәрәзәсен,
Яшь егетләр килеп чирткәннәр.

Дәфтәр бите кадәр генә төштә,
Ерак китми лампа яктысы.
Күзләренә яшьлек дәрте тулган,
Уйнап торган яшен чаткысы.

Казан тулы урыйн аш кайнаган,
Өметләнеп кемне көткәннәр.
Киләчәккә сабыр караш ташлап,
Бәйрәмнәргә күлмәк теккәннәр.

Зар еламый кайнар яшькә төелеп,
Заман йөген тартып үскәннәр.
Көзләр җитсә, егет кыз ярәшкән,
Ә, кызлары, килен төшкәннәр.

Сабырлык та,горурлык та булган,
Сер бирмәгән авыр минутта.
Кемнәрнедер күңел кызганасың,
Ул чакларын кемдер оныта.

Кайсы заман, кайсы чор булса да,
Кызлар сөйгән, кызлар сөелгән.
Безнең чорда матур яшәгәнгә,
Алар язмышына сөенәм.

# Киртәләр бар юлларымда

Тар сукмактан чыгам олы юлга,
Мине көтә алда максатым.
Үземне бер ерак сәфәр кылган,
Ялгыз юлаучыга охшаттым.

Киртәләр күп, адым саен күрәм,
Сүтеп ташлыйм, барын җимерәм.
Зәңгәр офыкларым яулык болгый,
Артка чикмим баскан җиремнән.

Каршы искән хәтәр җилгә барам,
Аягымнан берүк екмасын.
Ышанычым яшәү дәрте бирә,
Афәтеннән Ходай сакласын.

Аякларым тала - алга атлыйм,
Тирәнәя сулыш һаман да.
Мин аңладым - теләкләргә ирешү,
Җиңел түгел безнең заманда.

* * *

## Көтеп яшим

Мин яшәдем гомер буе көтеп,
Килер көнне атыр таңымны.
Яшәү дәрте җанда бөркет булып,
Күңел күкләрендә кагынды.

Көтеп алам елның дүрт фасылын,
Күзалладым аны төрлечә.
Назы, яме белән сокланырлык,
Йөрәк түзми һичтә күрмичә.

Көтеп яшим килер язларымны,
Кояш мәрхәмәте күбрәк.
Тормыш бишегендә тирбәләмен,
Дөньяларым була түгәрәк.

Көтүләре озак тоела бит,
Өметләрем бушка калмасын.
Ихтыярны, көчне җыям бергә,
Сабыр канатларым талмасын.

Очрашуны, күрешүне көтәм,
Киләчәккә барын юрадым.
Ходай бирсен саулык-иминлекне,
Өзелмәсен гомер юлларым.

* * *

## Кайгы килсә

Көтмәгәндә кайгы килеп,
Башны түбән идерә.
Йөзләремә сырлар салып,
Утларында көйдерә.

Моңсулата, хәлсезләтә,
Ихтыяр-көчен сыный.
Һич кенә дә исәпләшми,
Суыра, җанны сорый.

Мөшкел хәлгә юлыккачтын,
Җаен тапмый баш ватам.
Читлектәге тоткын кошка,
Үземне тик охшатам.

Кайгы шәүләсе каплагач,
Кояшымны, аемны.
Бер юаныч таба алмыйм,
Чуалтты бар уемны.

Кайгы җиле кага-суга,
Бер мәл екты аяктан.
Бирешмәдем дип әйтергә,
Күз яшьләнде ояттан.

* * *

## Түрәләр төрле була

Төрле түрәләрне күрдем,
Гамьсезен, явызын да.
Сүгенә, төкерек чәчеп,
Мат сүзе авызында.

Берсе бармак селкеп яный,
Усаллыгын күрсәтте.
Әйтерсеңлә баш өстендә,
Уйната зур күсәкне.

Бер гамьсезе кулы белән,
Өстәлне төя генә.
Куркытам, дип уйлагандыр,
Ирешми теләгенә.

Түрәләргә һич бер кайчан,
Йөзек кашы булмадым.
Эт белсен аның сәбәбен,
Мин алардан уңмадым.

Барында күреп үткәрдем,
Мактамыйм, хурламадым.
Алар өчен тос әйтмәдем,
Җырларын җырламадым.

* * *

# Сер түгел

Сарык елында туганмын,
Сер сакламыйм бу хакта.
Ел фасылы төрле була,
Олы мәгънә ята.

Көтүдәге сарык кебек,
Кудылар да бүлделәр.
Әллә дөнья мәхлугы дип,
Юаш итеп белделәр.

Тешләшмимен, тибешмимен,
Үз сукмагымнан йөрдем.
Кояшлы көнемдә булды,
Айсыз төнендә күрдем.

Сарык елында тугачтын,
Мин арыслан булалмам.
Рәнҗемәдем, ихтыярың,
Тәкъдиреңә и, аллам.

Канымда давыл уйнамый,
Уйларымнан сүреләм.
Яманлык кылмыйм кешегә,
Шөкер итәм, сөенәм.

* * *

# Йолдызлар җиле

Күк гөмбәзен бизәп яна,
Йолдызлар балкый төнен.
Үз ара алар серләшә,
Аңлармын бәлки телен.

Оясындагы кош кебек,
Йолдызлар канат кага.
Галәм түреннән ишетәм,
Илаһи моңнар ага.

Учак төсле күрәп тора,
Йолдызлар җемелдәшә.
Күзләрен кыса, елмая,
Ераклардан эндәшә.

Көмеш тәңкәләр күк чыңлап,
Йолдызлар явар төсле.
Төрле почмагыннан күкнең,
Җиргә юл сузып төште.

Күңел кошымны очырам,
Күреп кайтсын бар җирне.
Хушландыра сихри төне,
Назлы йолдызлар җиле.

* * *

## Хыяллар белән яшим

Башым түбән иелгәнсең,
Күтәрелми көчем юк.
Бетмәс мәшәкатьләр артты,
Мине аңлар кешем юк.

Өметләремне акламый,
Җилләр исә каршыга.
Чәчемә кыраулар төште,
Карлар яуды башыма.

Имәннәр кебек чайкалам,
Уш-зиһен җыеп торам.
Абынганда, егылганда,
Башымны җиргә орам.

Үз җилкәмә төшкәч белдем,
Бу заман авырлыгы.
Җитәр микән мондый чакта,
Һәркемнең сабырлыгы.

Яшәү хәстәрен күрәмен,
Утка, суга керсәм дә.
Хыяллар белән яшимен,
Төрле уйда йөрсәм дә.

* * *

## Кулымда тормыш тезгене

Кулым белән кош тотарга йөрдем,
Йолдызларны күктән чүпләдем.
Егәрлегем җитә, дәртем таша,
Йөгереп үтәм вакыт чикләрен.

Урал бөркетенә мин тиңләшәм,
Кыяларның мендем очына.
Юлда урап узам киртәләрне,
Галәм капкалары ачыла.

Үз кулымда тотам җибәрмичә,
Ычкынмады тормыш тезгене.
Күкрәүләргә, яшнәүләргә тиңлим,
Гомеремнең гүзәл мизгеле.

Ашыктыра вакыт кабаланам,
Бар тарафка карап кул сузам.
Илләр гизәм, диңгезләрне кичәм,
Коры килеш чыгам мин судан.

Максат куям, ихтыярым җитә,
Теләгемә күпчак ирештем.
Аптырашта калмыйм икеләнеп,
Җаен табам белеп һәр эшнең.

* * *

## Хәлең мөшкел

Сорашмадым үткәнеңне,
Сакла барсын үзеңдә.
Маңгаеңда сырлар ята,
Моңсулык бар йөзеңдә.

Әйтмәсәңдә хәлең мөшкел,
Бер караштан аңладым.
Өзгәләнгән бәгерләрең,
Язмышыңнан уңмадың.

Кайгы җилләре сине дә,
Каккандыр да суккандыр.
Юлларыңа киртә булып,
Этләр өреп чыккандыр.

Алдангансың мәхәббәттә,
Күз яшьләрен түктеңме.
Гашыйк итәр язларыңны,
Шат көннәрне көттеңме.

Сукмагыңда адашкансың,
Саташулы төшләрнең.
Йөзеңә чыккан чагыла,
Күңел кичерешләрең.

* * *

# Ил язмышы борчый

Илем өчен бик тә борчыламын,
Бүлгәлиләр сатып җир-суын.
Әфәнделәр хуҗа булып калгач,
Күпме түгәр халык йөз суын.

Базар заманына калгачтанмы,
Минәүшикләр эше сатышу.
Мал мөлкәте җыю, байлык туплау,
Талау, урлау, көчләү, атышу.

Бу мәхшәрне ничек аңлап була,
Ата-баба рухы ни әйтер.
Сүзсез калдык, күзне йоммыйк әле,
Йодрыкларга кулны кирәктер.

Әзме илгә канын, җанын биргән,
Кеше гомерләре өзелде.
Авыр хәлгә калдык алдангачтын,
Сабыр итә халык түземле.

Илдә иман качты, кыйбласы юк,
Ник ышаныч калмый чак кына.
Әфәнделәр тагын корбан сорый,
Көрәш мәйданына чакыра.

* * *

## Дөнья яктысы

Гомер юлын кичкән кеше,
Күп төрлегә төрләнә.
Өскә кигән күлмәкләр дә,
Күңелләр дә керләнә.

Тормыш ачысын тоямын,
Күрәм кайгы карасын.
Үлчәүләргә салып булмый,
Йөрәкнең бар ярасын.

Юллар озын, адаштыра,
Уйлар диңгезе тирән.
Бер сер булып калсын әле,
Башны имәдем түбән.

Җил-давыллар кага-суга,
Аяктан кайчак ега.
Бер ходайга ялварамын,
Укырга беләм дога.

Хәвефле хәлләрдә читен
Җанны да яклыйсы бар.
Рәхмәте зур кешеләргә
Дөньяның яктысы бар.

* * *

# Күкри яшьлек җырыбыз

Вакыт агышы юмады,
Йөрәктәге ярамны.
Кайтавазлар булып кайтты,
Хәтирәләр яңарды.

Әйтерсең болытлар шаулый,
Ташулар ярга какты.
Күңелнең бер почмагында
Ал таңнар булып атты.

Шиңгән гөлләрне терелтә,
Сүнгән хисләр җанлана.
Давыллы кичерешләрем,
Кызык, шаулы замана.

Таныш моңнар урап кайтты,
Күп еллар аша исән.
Бу җыр дәртле, хата булмас,
Җаныма якын, дисәм.

Күкрәп күңелем күгендә,
Яшеннәр кебек яшьнәр.
Безнең яшьлек җырыбыз бу,
Онытылмас, мәңге яшәр.

* * *

# Гомер уза

Йөгереп кенә көннәр үтеп китә,
Еллар кочагына ташлана.
Төннәрен дә сизмим йокым белән,
Шаулы хезмәт иртә башлана.

Галәм йөзә, вакыт дәрьясында,
Бер мизгелгә хәтта туктамый.
Күзгә чалынса да, төрле төстә,
Кеше кулы капшап тоталмый.

Ямьле җәй аеның хет бер көнен,
Тотып булса икән тезгендә.
Йөзләремә шатлыкларым чыгар,
Якты нур балкыр күземдә.

Бер-бер артлы көннәр өзелә сыман,
Әйтерсеңлә яфрак коела.
Тормыштагы бөтен куанычлар,
Төш шикелле кыска тоела.

Бу мәңгелек вакыт кануннары,
Минуты да аның кичекми.
Гомер уза, сизелми дә кала,
Моң-зарымны минем ишетми.

* * *

# Дусларым күп

Дусларым күп бу дөньяда,
Мактанам алар белән.
Кичерәм горурлык хисе,
Дуслык кадерен беләм.
Дуслар мине юлдаш итте,
Тормышта була терәк.
Кисәттеләр бармак төртеп,
Бары яхшылык теләп.
Серләремне уртак итеп,
Кайгыларны тарата.
Гомеренә тир түгәләр,
Бар да тормыш ярата.
Уртак безнең максатыбыз,
Уртак безнең теләк тә.
Шәфкатьлелек, изгелек тә,
Яши безнең йөрәктә.
Ятлар да шикләнеп карый,
Гайбәтче күп, онытмыйк,
Дуслык үзе зур хәзинә,
Аны мәңге югалтмыйк.

* * *

# Мине аңларсың, бәлки...

Ильдарга

Мин киткәндә син йокыда калдың,
Уятырга һич тә кыймадым.
Гомерлеккә аерылабыз диеп,
Бишегеңә карап уйландым.
Кылган эшкә нигә үкенергә,
Аерылмаслык түгел сәбәбе.
Авырлыклар барын тоймагансың,
Барысыннан ерак син әле.
Без ирләрчә булаек, дип әйтсәм,
Ничегрәк мине аңларсың.
Сукмакларың олы юлга чыгар,
Син тормышта, бәлки, уңарсың.
Вак җаннарга килеп юлыкмасаң,
Кичермәсәң, вөҗдан газабын.
Яшәү мәгънәсенә төшенмәсәң,
Сөйләсәм дә баштан узганын,
Атта да бар, тәртәдә дә була,
Хөкем чыгарырга җыенсаң.
Ак өстенә, кара тап та төшә,
Әмәл эзләп кара юалсаң.
Көнчеллекне, хыянәтне беләм,
Син күрмәдең ирләр ярасын.
Мин югалткан бәхет табылмады,
Бәлки, аны эзләп табарсың.

# Агын да бар күргән, күген дә

Агын да бар күргән, күгендә бар,
Утка кердем, суга төштем мин.
Ачысын да, төчесен дә таныйм,
Чүмечемә салып эчтем мин.
Тормыш өресен дә җыеп эчтем,
Нужда калачын да ашадым.
Йодрыклап якалашкан чакта,
Дон-кихотка мин дә охшадым.
Гаеплегә хөкем чыгарылсын,
Көчсезләргә көчен күрсәтә.
Дус-иш булып башта кыланганнар,
Үрелделәр кабат күсәккә.
Җил-давылга юлыкканда белдем,
Күргәнем күп булды куркакны.
Шәйләмичә, һич тә уйламыйча,
Күкрәк куеп атлыйм бер катлы.
Үлчәмичә кайчак сөйләшәм дә,
Авызымны үзем пешерәм.
Юашландым, сабырландым инде,
Күп могҗиза баштан кичерәм,
Үткәннәрне искә төшерәм.

* * *

# Мин ышанам көчемә

Кулым талып, башым әйләнсә дә,
Тормыш йөген инде күтәрәм.
Күп кешеләр миңа ышанмас та,
Бер сер итеп саклыйм күптәннән.
Төрле була юллар,язмышлар да,
Җилләр исә каршы ирләргә,
Гомер йомгагымны сүтә-сүтә,
Мин үреләм әкрен үрләргә,
Еллар чиксез, юлларым да озын,
Кем чыгалыр аның очына.
Килер көнгә шатлыгымны итәм,
Гөл-чәчкәләр җыям учыма.
Җир көч бирә арган чакларымда,
Үргә авыр атлап менүем.
Берәүләргә куанычлы булган,
Бу дөньяга минем килүем.
Үз юлымны, үз хәлемне белеп,
Мин ышанам булган көчемә,
Яшәү яме илдә артыр гына,
Язлар алып килсәм кешегә.

* * *

# Вакыт сагында тора

Күктә йолдызлар атыла,
Аккан чишмәләр кибә.
Гел үзгәреп тора дөнья,
Нишләсен, йөрәк күнә.
Кеше гомерендә яшьнәп,
Шәфактәй балкып сүнә.
Җирнең назлы чәчәкләре,
Вакытсыз кайчак шиңә.
Таш ватыла, таулар чүгә,
Аянычлы бу дөнья.
Юксындыра, шомландыра,
Күңелемә шик куя.
Мәңгелек булып калырга,
Кемнәр дәгъвә кыла?
Кичен шаулаган ташулар,
Иртәсен тынып кала.
Юллар кайтмый үткәннәргә,
Узылган ерак ара.
Елларны, чорларны сынап,
Вакыт сагында тора.

* * *

# Поездлар узган чакта...

Поездлар узган чакта...
Поездлар гөрләп узалар,
Белмим кайсы якларга,
Иләсләнеп тора күңел,
Нигә шундый чакларда
Поездлар ашыгып чаба,
Тәгәрмәчләр җырлады,
Шаулап үтеп китә сыман,
Гүзәл яшьлек еллары.
Еракка чакырып тора,
Таулар, кырлар,күлләр дә,
Юлдаш итәр, сәфәр чыксам,
Мине әллә кемнәр дә.
Вагоннар тезелеп үтә,
Карап калам борчылып,
Канат куя йөрәгемә,
Күңел тора очынып.

* * *

# Мәҗлес

Икмәкләрнең, сыйның тулы чагы,
Өстәлләргә тезеп куелган.
Шаулап тора, гөрләп тора бүген,
Табыннарга дуслар җыелган.
Дус-ишләрем, матур елмаялар,
Күркәмләтеп безнең табынны.
Гармун моңы, җыр тавышы ничек,
Күңел кылларына кагылды.
Мәҗлесләрдә шатлык кичерәмен,
Сый-хөрмәтнең күрәм олысын.
Бергә чакның кадерләрен белеп,
Бакалларның тотыйк тулысын!
Гомерлеккә безнең истә калсын,
Бергә булган изге сәгатьләр.
Очраштырмый, кайчак күрештерми,
Бу тормышта төрле сәбәпләр.
Мәҗлес ямьле, табыныбыз сыйлы,
Шатлыгыбыз уртак ачыклыйк,
Дөнья имин тора, көннәр матур,
Хушлашырга әле ашыкмыйк!

* * *

# Көндә казлар куасың

Оя, оя булып йөри,
Каз бәбкәләрең бергә.
Изге ният, өмет белән,
Яши, әни гомергә.
Мәшәкатьләрең дә бетми,
Эш яраттың син үзең.
Көненә ничә мәртәбә,
Юлларга була күзең.
Бер ялгызың су буеннан,
Болыннардан урыйсың.
Төш күрсәң дә, гел яхшыга,
Улларыңа юрыйсың.
Өлеш чыгарасың безгә.
Атап казлар куясың.
Уйланмыйча, борчылмыйча,
Торган мәлең кая соң?
Карашыңны төбәп ерак,
Казларыңны парлыйсың.
Максат куеп яшәгәнгә,
Бу тормышта армыйсың.

* * *

## Мине табарсың

Юксынганда сәхрәләргә чык син,
Күңел сагышларың таралсын.
Тракторлар гөрли киң кырларда,
Буразнадан килеп табарсың.
Авыр уйларыңны читкә ташла,
Башка хисләр синдә яңарсын.
Чыклар ярып болыннарга узам,
Печән покосыннан табарсың.
Йөргән сукмагымда гөлләр үскән,
Түшләреңә өзеп кадарсың.
Хезмәт дәрте белән янып яшим,
Күзләремә карап танырсың.
Айлы төндә урамнарга чыксаң,
Гармун тавышларын тыңларсың,
Юксынганда, борчылганда мине,
Җырларымнан килеп табарсың.

* * *

# Дөнья артыннан кумыйм

Дөнья артыннан кумадым,
Кызыкмадым малына.
Хезмәт шатлыгын кичерәм,
Канәгатьмен барына.
Алыш-биреш иткәнем юк,
Эзләмәдем табыш та.
Үз шөгеле белән яши,
Минем бөтен таныш та.
Җиңел кәсепкә кызмадым,
Иген игәм ничек тә.
Нәфселәшкән кеше дә бар,
Бер тиенне биш итә.
Кода-кодагыйлык яши,
Бетми һаман ялагай.
Табыш артыннан йөрмәдем,
Миңа алай ярамый.
Нәселемә тап төшермәм,
Яман атым чыкмасын.
Гамьсезлектән, мәнсезлектән,
Аллам үзе сакласын.

* * *

# Елмаюың калсын

Матур яшьлегемне җырга кушып,
Колак салсаң әйткән сүземә.
Син көлгәндә дөнья балкып китсен,
Якты нурлар чыксын йөзеңә.
Елмаюың күз алдымда кала,
Шат булуың сиңа килешә.
Иңнәреңә төшсен кара чәчең,
Бер мизгелгә калсын минемчә.
Җирнең яме арта гөлләр шытса,
Яшь бөреләр күкрәп тишелсә.
Кыгыраулар сыман чыңлап кала,
Көлгән тавышларың ишетелсә.
Уйларыма якты нур бөркисең,
Томан пәрдәләрен тараттың.
Карашымны минем үзеңә алдың,
Назлы кошым сине яраттым.
Моңсуланма, елмаеп тор һәрчак,
Мин бит мохтаҗ синең назыңа.
Ир-егетнең канатлары талмас,
Шөһрәт кирәк аңа аз гына.

## Таллар булып бөгеләм

Бер йодрыкка төйнәләм,
Таллар булып сыгылам.
Җаныма урын табалмый,
Бәргәләнәм, сугылам.
Бар көчемне мин җыямын,
Каным таша тәнемдә.
Сүнмәс утлар кайнап тора,
Бу тормышның төбендә.
Йөрәк янып күмерләнә,
Сары көйде йөзләрем.
Ерак калган шат көннәрем,
Үткәнен дә сизмәдем.
Бәргәләнәм, өзгәләнәм,
Хәлләремне кем белә?
Заман ишетми зарымны,
Шау-шуына күмелә.

## Нигә газап чигәргә

Елмайды да узып китте,
Их, белергә ниятен,
Белмисең дә йөрәгемне,
Үзең белән ияртттең.
Киткән юлыңа карадым,
Күз нурларымны түгеп.
Татлы төш шикелле генә,
Калдым тик сине күреп.
«Йөрәгем гашыйк булма,- дим,
Узган-барган чибәргә.
Бу соңгысы булмас әле,
Нигә газап чигәргә?».

# Бар кеше дә шагыйрь

Бер карасаң бар кеше  дә шагыйрь,
Шигырь язмый хәзер кем генә?
Еллар аша гасырларга кайсы,
Барып җитәр ансын кем белә?
Төрле шагыйрь төрле язмыш белән
Башлап китә тәүдә юл башын.
Ялгыз каршыладык Кол Галине,
Күпләр белми аның юлдашын.
Һәр дәвернең үз шагыйре булган,
Кәмитчесе, булган әдибе.
Акны кара дип әйткәне бар,
Бу кешеләр бар да гаделме?
Үткәннәргә һәрчак тарих шаһит,
Фаҗигаләр әзме күмелә.
Йөрәккә моң, дәртле җырлар алып
Шагыйрь керә күңел түренә.
Ташу суы итә хисләреңне,
Көчен таба, сибә энҗесен.
Кирәк чакта үз гомерен биргән,
Фида кылган җаннар әзме соң?
Мәңгелеккә кемнәр дәгъвә кыла,
Күп исемнәр инде җуела.
Узган-барган бар юлаучы хәзер,
Шигырь мәйданына җыела.
Шагыйрь булып туган кеше генә,
Күкри, яшьни, яна дөньяда.
Илһамланып, канатланып яши,
Тирәнрәк йөзә уйларда.

# Теләкләргә ирешмәдек

Теләкләргә ирешәлми калдык,
Күңелебез әллә сүрелде.
Сәламемне сиңа җиткермәсләр,
Яфрак булып җиргә сибелде.
Юллар очы килеп кушылмады,
Ике ярда басып торабыз.
Йөрәкләргә күпер салалмадык,
Тоташмады безнең арабыз.
Шик астына куйды уйлар мине,
Борчуларым бетмәс озакка.
Шатлыкларны көтеп яшәгәндә,
Мәхәббәтем салды газапка.
Акланырга сәбәпләрен таптык,
Вәгъдәләрең очты җилләргә.
Кемнең хыянәте булып шулай,
Авыр сагыш төште иңнәргә.
Мәхәббәткә җиңел караганбыз,
Бәгырьләрне телеп тилмертте.
Башны иеп сүзсез калалмадым,
Телсезне дә, хәтта телле итте.
Сөю хисе җанны җилкетте.

* * *

# Карашыңны сагынам

Күзгә карап күзләр очраша,
Бер ноктага килеп туктады.
Йокыларым качты керфегемнән,
Йөрәгемне сүнмәс ут ала.
Карашыңда сөю сагышлары,
Яшерен моң тулып түгелде.
Яз гөлләрен җыеп китергәнсең,
Төштә күргән кебек кенә булдым,
Татлы өметләрем терелде.
Бер мизгелдә китеп югалдың,
Борчуларга салма юксынганда,
Очраштырмас бәлки юлларым.
Карашыңны сагынам бер күрсәм дә,
Ятларга мин яшерен сер итәм.
Узган шатлык кына булсаң, онытам,
Көткән бәхет булсаң, кил иркәм!

* * *

## Сөюдә сыналасың

Чәч толымың иңнәреңдә,
Сүтәсеңдер хәзер дә.
Яз кояшы кебек калган,
Көлгән чагың хәтердә.
Ул чагында горур идең,
Борчыларга белмәдең.
Нинди кыяфәткә кердең,
Ничә төргә төрләндең.
Күзеңдәге утлы ялкын,
Балкып бер дөрләгәндер.
Яшьлек дәрте, кайнар хисләр,
Тынгы да бирмәгәндер.
Ашкындың да, җилкендең дә,
Барып чыктың чигенә.
Мәхәббәттә алданучы,
Түгел ләсә син генә.
Ялгыз гомер кичерәсең,
Сөюдә сыналгансың.
Бәхет белән афәт янәш,
Адымлап санагансың.
Назлы гөлгә тиз кагыла,
Иртә кырау тигәндер.
Язмышыңнан кагылмыйсың,
Канатларың көйгәндер.

# Гомер сукмагы

*(поэма)*

Тәрәзәмнең пәрдәләрен ачтым
Урамнарга төшә карашым.
Ак энҗеләр кебек карлар яуган,
Таң эреткән төннең карасын.

Кыш иртәсен серле тынлык били,
Агачларга көмеш бәс каткан.
Күзләремә тулды якты нурлар,
Юрган булып җиргә кар яткан.

Декабрьнең соңгы көне бүген,
Сагышлы моң җанда терелә.
Төрле уйлар башка килеп басты,
Төшенәлмим үзем серенә.

Сусаганмын аклык-сафлыкларга,
Сизелмидә вакыт агышы.
Фани дөнья үзгәрә дә тора,
Ак пәрдәләр корган каршыма.

Кар өсләре якты мәрҗән төсле,
Җем-җем итә күзләр камаша.
Тирә-юньгә бәйрәм төсе кергән,
Кыш күрсәтә олы тамаша.

Урам читендәге каеннарда,
Иңнәренә салган ак шәлне.
Кызлар кебек мине сокландыра,
Канатлана хисләр бу мәлне.

Чәчәк аткан чагы хыялымның,
Яшьлегенә кайтып урадым.
Изге максат белән туган җирдә,
Күкрәгендә яшим Уралның.

Кыш аенда усал ир холкы бар,
Кырыс та ул, ыжгыр, суык та.
Күз ачмаслык бураннары улый,
Ачы җилләр дулый чынлыкта.

Иртәләрем тыныч уза да соң,
Моңсулата мине кичләрем.
Ваклыклардан өстен булсам иде,
Саташулы күргән төшләрем.

Көнем-төнем тоташ үтеп тора,
Сәгать чылбыры күк тезелеп.
Маңгай сырларына күзем төшә,
Көзгеләргә карыйм өзелеп.

Яңа елым ишек кага килеп,
Дусларымны җыям кичәгә.
Илем имин, дөнья тыныч булсын,
Шатлыкларым беләм килсәнә.

Кыңгыраулы пар атларда чыңлап,
Бер йөрисе килә бәйрәмдә.
Мине яшьләр аңламаста хәзер,
Машинада урам әйләнә.

Бу кичәдә шампан шәрабләрен,
Бәллүр бокалларга салырмын.
Кайсы дуслар  табынымда булмас,
Сынаса да язмыш сабырмын.

Бер югалту күрми кем яшәгән,
Аянычлы хәлләр кичердем.
Дөнья куйган күпме дусларымны,
Юксындыра, искә төшерәм.

Иртән торып күзне ачтым исә,
Күрәм дөнья ничек чупләнгән.
Күкләр чатный, җир тетрәп куя,
Шомланамын, кайчак шикләнәм.

Кыш мизгеле күңел түрендәсең,
Тәңкә карлар яуды күп тапкыр.
Бу көн хәтеремдә калыр озак,
Чия чәчәге кук ап-актыр.

Көмеш кыңгыраулар чыңы тансык,
Гармуннарның моңы таралсын.
Онытырга исәп ваклыкларны,
Якты хисләр җанда яңарсын.

Көннәремне, елларымны барлыйм,
Шигырь юлларына тезәмен.
Кар бураннар уртасында калам,
Салкын җилләренә түзәмен.

Ихтыярны - көчне җыеп яшим,
Кулга алам һәрчак үземне.
Үз юлында, үз сукмагымдамын,
Мин кояшка куям йөземне.

Диңгез кебек тирән уйда калам,
Тапмыйм аның очын, азагын.
Исән калып яшәвемә сөенәм,
Күрсәмдә күп, тормыш газабын.

Кышларныңда күп төрлесен күрдем,
Кары-бозы яуды башыма.
Табигатьнең үз кануны яши,
Хөкем карары бер барсына.

Кара төндә бураннарда калып,
Юлларымнан язып адаштым.
Йөрәгемне чәнчү алганда да,
Тормыш белән һәрчак аңлаштым.

Җан өшегән сәгатьләре була,
Үзәгенә төшә кешенең.
Мин көненә ничә төрле булам,
Язмыш каһәренә төшенәм.

Офык артындамы көткән бәхетем,
Читләп узалырмын киртәне.
Мине алда олы сынау көтә.
Сабырлыгым гына җитәрме.

Күңелемә күчсен аклык-сафлык,
Гомеремнең якты мизгеле.
Матурлыкның, гүзәллекнең дә бит,
Үз вакыты була билгеле.

Кыш аеның йомартлыгын тоям,
Аклык,пакълек, сафлык өләшә.
Җир өсләре нур балкытып торган,
Җәүһәр ташларына тиңләшә.

Ел фасылы чылбырында тора,
Язны, җәйне, көзне, кышны да.
Вакыт үлчәвендә тора барда,
Җирдә аунап яткан ташлар да.

Галәм киңлегендә вакыт ага,
Тормыш экранында чагыла.
Сунамилар шашты, ай тотылды,
Күргәнем бар шундый чагында.

Көнне караңгы төн алмаштыра,
Күкне бизәп йолдызлар яна.
Миллион еллар кабатланган шулай,
Бар кешелек күнеккән аңа.

Гомер сукмагымда бар күргәнем,
Хәтер китабыма языла.
Ерак киләчәкне күзем белән,
Бер күрергә иде аз гына.

Сукмагымда төрле хәлләр очрый,
Туктамадым көнен-төнен дә.
Упкыннарны үттем, дарья кичтем,
Яшәү дәрте сүнми күңелдә.

Яз тавышы керә колагыма,
Тамчылары тама тып та тып.
Кыйбыла яктан Саба җиле исә,
Кулдан килми, булмый туктатып.

Вакыт җиткәч карлар эреп ага,
Ерганаклар гөрләп юл салыр.
Бер мизгелдә барын хәл итәсең,
Ашыкма әле вакыт, ит сабыр.

Узган язлар төшләремә керә,
Тансык итәм сулар һавасын.
Сәхрәләргә чыгып бер урасам,
Чәчкәләрдән илһам аласың.

Шәмдәлләрдә янган шәмнәр кебек,
Юкка гына йөрәк янмасын.
Язлар җиткәч кәккүкләрем кайтып,
Гомер озынлыгын санасын.

Ышанычым мине ташламады,
Кыш артында көткән язым бар.
Хәсрәт күлләреннән тартып алдым,
Куанычың, ямең, назың бар.

Көндәлегем ята өстәлемдә,
Һәр көнемне санап барамын.
Көн кояшлы, төнем айлы булса,
Сөенәмен, сабый баламын.

Афәтләргә бердә юлыкмыйча,
Кайтсын иде кошлар иленә.
Тирәкләрем күптән сагынып көтә,
Моңсулыгы күзгә күренә.

Кош оясы агач башларында,
Бала бишеге күк тирбәлә.
Дәртләндереп ташкан хисләр белән,
Җирдә моңнар, җырлар тәрләнә.

Яшьлек ямен язлар алып килә,
Шанлы күкрәүләре күкрәсен.
Зәңгәр апрельнең иртәләрен,
Ташуларын килә күрәсем.

Тирәкләрнең бөреләрен көтәм,
Куанычым сыймый күңелгә.
Дарьяларым ташып ташыганда,
Дөнья шау-шуларга күмелә.

Хәтеремдә калган узган язлар,
Һәрчак бага күңел күзләрем.
Гомеремдә күп югалту күрдем,
Үлчәп тора вакыт бизмәнең.

Бер кем белән тормыш исәпләшми,
Чыгара да хөкем-карарын.
Киләчәккә барыр юлларыма,
Гел ышаныч белән карадым.

Кошлар нәселеннән булмагачтын,
Төшәм җирдән түбән тәгәрәп.
Кулны тота тормыш мәшәкате,
Эшләрем күп булмый төгәлләп.

Ачы күз яшем дә күп түгелде,
Горур башта түбән иелә.
Ни нахакка кеше газаплана,
Нинди каһәр төшкән бу илгә.

Ач бүреләр төннә улаганда,
Күзләремә йокы кермәде.
Фәкыйрьлектән, мохтаҗлыктан башка,
Безнең халык берни күрмәде.

Халык зарын ишетеп яшәдем,
Кайгы-хәсрәт ашкан башымнан.
Күпме генә гомер кичерәсең,
Күреп беләм кабер ташыннан.

Аякларым җирдән атлаганда,
Үз кыйбылама кирәк барырга.
Вакыт ага туктап калалмыймын,
Хакым юк шул минем арырга.

Бар күргәнем күңелемә күчеп,
Җырым булып туа дөньяга.
Йөрәкләрдән йөрәкләргә күчеп,
Җанны тетрәндергән моң ага.

Күпме язлар гомеремдә узды,
Өмет белән көтәм киләсен.
Күзен ачкан агач бөреләрен,
Ташуларны килә күрәсем.

Карлар-бозлар җирдә калмас әле,
Кояш кына көлсен эрерләр.
Каршылаудан, озатудан гына,
Торамы соң әллә гомерләр?

## II

Гомер сукмагыңнан атлап киләм,
Якты язга, яшел җәйләргә.
Яңа көнгә кергәч сәлам бирәм,
Аккан суга, искән җилләргә.

Учактагы утлар кебек дөрлим,
Казанында кайныйм җәй җитсә.
Борчыламын, үкенәмен бары,
Бер файдасыз әгәр көн үтсә.

Сәхрә-кырда уза озын көнем,
Сабан тотып үстем басуда.
Тузан йотып арып эштән кайтам,
Яшәгәндә күрдем барсын да.

Фани дөнья алдый кешеләрне,
Ике яшәмәгән бер кем дә.
Таулар чүгә, чишмә суы кибә,
Төрле хәлләр очрый бу көндә.

Җәй көнендә кулым бушап тормый,
Көрәк, сәнәк, чалгы тотамын.
Болыннарда, иген кырларында,
Тугайларның җырын отамын.

Игенче дә, көтүче дә булдым,
Ташта ваттым, йортта бурадым.
Горурлану, бер масаю белән,
Басулардан ничә урадым.

Җир хуҗасы итеп хис итәмен,
Тамырларым ята тирәндә.
Хезмәтемә көч тә, дәрт тә арта,
Иген басуларын күрәм дә.

Кызган таба кебек куырып ала,
Ашыктыра мине эшләрем.
Игенченең алы-ялы булмый,
Йокыларны бүлә төшләрем.

Ризык җыярга да вакыт тапмый,
Басу түрләрендә каламын.
Яңгыр яуды башка, яшен яшьни,
Ихтыяр да, көч тә табамын.

Рәхмәтлемен үз шөгелем булгач,
Язмыш мине җиргә бәйләдең.
Игеннәрем уңа, барын җыям,
Ямьле уза уңыш бәйрәмем.

Кайсы елны яңгыры да яумый,
Кайсы җәйдә койды чиләкләп.
Көтелмәгән чакта болыт килеп,
Бозлары да яуды сирәкләп.

Еллар акрын гына уза тора,
Гомер сукмагымнан киләмен.
Әзме сулар акты, җилләр иске,
Яшәү рәвешенә күнәмен.

Дусларымны һаман югалтамын,
Җирдә арта кеше кабере.
Сирәк күрешәбез, үкендерә,
Бергә булган көннәр кадерле.

Моң-сагышка күңел тулышканда,
Сер итәмен кемнәр аңлар соң.
Болыт булып килде кайгыларым,
Читләп узмый адәм баласын.

Учак уты кебек бар да сүнә,
Вакыт яңгырында юыла.
И, кояшым, күктә мәңгелексең,
Юлдаш бул син гомер юлыма.

Тормыш кочагында назла әле,
Золым-җәберенне күрсәтмә.
Чуар заманга туры килдем,
Гаделсезлек, ачлык кисәтә.

Илләр күрдем, дөнья гизеп йөрдем,
Ни күрсәм дә килә яшисе.
Күкләрендә бер күрәсе иде,
Яшеннәре булып яшнисе.

Йөрәк кенә түзсен, чыдар микән,
Йөз төрлегә көндә төрләнәм.
Тәндә каным кызып таша,
Утлы ялкын җанга үрләгән.

Гомер сукмаклары алып килде,
Сары көзләремә керәмен.
Чана эзе кебек сызылып ята,
Йөзләремдә сырлар күрәмен.

Сары ялкын уртасында калдым,
Моңсу уйлар керде башыма.
Агач яфракларын җилләр түгә,
Шыбыр-шыбыр урам ташына.

Яшьлек язым бик еракта калдың,
Көзләрдән соң нәрсә көтәрмен.
Дөнья мәшәкатең миннән калыр,
Мәңгелеккә бер көн китәрмен.

Кош юллары озын күзәтәмен,
Кыр казлары сез дә китәсез.
Ялгыз кеше хәлен белмисез шул,
И, ямансу, моңсу итәсез.

Таш кыялар сыман өнсез калдым,
Ишетәмен галәм авазын.
Коеп яуган көзнең яңгырлары,
Юып алды яшьлегем назын.

Гармун күрегедәй сузып булмый,
Бик тә чикле кеше гомере.
Шаһит булам узган елларыма,
Бәгыремне алар кимерде.

Туып үскән җирем рәхмәтлемен,
Суын эчтем, икмәк ашаттың.
Сабырлыгың, юмартлыгың белән,
Үз анама сине охшаттым.

Җир җылысын һәрчак тоеп яшим,
Юк, шиңмәде күңел гөлләрем.
Гомер кузы, шәфак нуры кебек,
Җитә ахры сүнәр көннәрең.

Гомер сукмагында очрады,
Ятлар да бар, якын дуслар да.
Кара кайгыларда, шатлыкларда,
Күзем кызган асыл кошлар да.

Нидер җитми җирдә, кемнәрдер юк,
Иртәләрем нигә томанлы.
Мине биләп алган билгесезлек,
Диңгез төсле җәйрәп торамы.

Карлар күмәр, яңгыр суы юар,
Сукмагымда калган эзләрне.
Өмет белән киләчәккә карыйм,
Еллар чакырып кулын изәде.

* * *

# Эчтәлек

Дөнья ямен җибәрмик............................................ 5
Кешеләргә булсын кирәгем.................................. 6
Кояшым да аем да бул.............................................7
Туган җирдә мәхәббәтем..........................................8
Шатлыкларым уртак булсын....................................9
Куларымны канат итәм.......................................... 10
Офыкларга төшә кояш............................................ 11
Урманнарга керсәм................................................. 12
Мин яңалык көтәм.................................................. 13
Җырларым.............................................................. 14
Акчарлагым........................................................... 15
Кулым бушап тормый............................................. 16
Минем халкым........................................................ 17
Намусыма тап төшмәсен........................................ 18
Яшәвемне раслыйм..................................................19
Киләчәкне күзаллыйм............................................. 20
Язмышыма сокланырлык..........................................21
Күрәсем, беләсем килә........................................... 22
Минем өчен нигъмәтең күп.................................... 23
Юлларыбыз очраштырмас........................................24
Мин арыдым........................................................... 25
Яр башында куш каеннар....................................... 26
Сандугачлар кайтты................................................ 27
Гомернең якты мизгеле.......................................... 28
Мин тормышка гашыйк.......................................... 29
Кошлар юлга җыена................................................30
Онытырга кирәк......................................................31
Ай тотылган төн......................................................32
Ашыкма картлык килергә.......................................33
Каен үссен...............................................................34
Олы юлга чыгам...................................................... 35
Диңгез чакыра.........................................................36

Син язларны көтәсең.........................................37
Күкрәгемдә чишмә моңы бар...............................38
Җирдә яшәр хакым бар......................................39
Мин көч табам....................................................40
Адашкан болытлар.............................................41
Җыр көйлим.........................................................42
Уфа урамнары.....................................................43
Мәхәббәт сүрәсе.................................................44
Йөзләремдә көз сарысы.....................................45
Әни......................................................................46
Җанымны кызганмыймын....................................47
Никтер сулар болгана........................................48
Гомерлеккә сәямен.............................................49
Хозурланам.........................................................50
Көткән кешеләрем булсын.................................51
Авылга кайтам.....................................................52
Озак яттың авырып.............................................53
Тәүдә эш күрсәт..................................................54
Соңладык.............................................................55
Аңлаштык.............................................................56
Еллар һәм юллар.................................................57
Күңелемдә яз.......................................................58
Алыш....................................................................59
Шикләнеп карыйм................................................60
Язмыш сынавы....................................................61
Чияләр пешкән.....................................................62
Кәнтәй..................................................................63
Офык аша уза юлларым......................................64
Син кабызган утлар.............................................65
Соңлама син........................................................66
Җәй көннәре........................................................67
Язлар көлеп килә.................................................68
Тормыш упкынына ташланам.............................69
Планетада җиңү бәйрәме....................................70

Ялгыз кош зары....................................................71
Игенчеләр көткән көн..........................................72
Тәрәзәмне ачтым................................................73
Азгынлык.............................................................74
Кайтсам...............................................................75
Нәрсәдер җитми..................................................76
√Диңгез тирәнлеген күрәм..................................77
Гармун уза.........................................................78
Шундый мәлләр була..........................................79
Ләззәтләнеп........................................................80
Яз.....................................................................81
Күл өстендә тынлык...........................................82
Мин ишетәм шагыйрь җырларын...........................83
Сәхраләргә чыксам..............................................84
Дим ярында.........................................................85
Киләчәккә кала ышанычым.................................86
Агачларга үрли сарылык.......................................87
Вакыт җитте.......................................................88
Әдәпсезлек каян килә?.........................................89
Яшьлегемне эзлим...............................................90
Борчылма син, ана!.............................................91
Мөмкин булса аңлашу.........................................92
Үрмә гөләң булам................................................93
Дөнья өйрәтте......................................................94
Син язмышым......................................................95
Бер карашың җитә...............................................96
Якты таңнар көтәсең...........................................97
Мәхәббәтем гомерлек..........................................98
Игенче басу түрендә............................................99
Очрашкан мизгелләр..........................................100
Гомерләр...........................................................101
Очрашсак сүзләр бетми......................................102
Каен бөреләре ачыла..........................................103
Ир булырга кирәк...............................................104

Тыныч булсын дөньялар........................................105
Бөреләрем ачыла................................................106
Бер син генә түгел.............................................107
Юлдаш итәм әни үгетен..........................................108
Дусларым үз итә................................................109
Төрле кичерешләр...............................................110
Нинди заманага калдык..........................................111
Яфраклар серләшә...............................................112
Болыннарда чәчкә исе...........................................113
Йөрәк сагышы...................................................114
Киләчәк көн билгесез...........................................115
Вакытлар үтә...................................................116
Таңны көтәм....................................................117
Такыялар үрәм..................................................118
Авылыма кайтам.................................................119
Ходай, сабырлык бир............................................120
Үткәнемә карыйм................................................121
Җәйнең ямен алып киттең........................................122
Ихлас булу кирәк...............................................123
Яшьлегем тугаенда..............................................124
Миндә хушлашырмын..............................................125
Җаным җәрәхәтле................................................126
Рәсәй..........................................................127
Чибәркәем......................................................128
Яшел ялкын сүнә................................................129
Шук малайлар идек..............................................130
Усаллык бар....................................................131
Теләкләрем аклансын............................................132
Кем тормыш җаен belә...........................................133
Шик астына куя.................................................134
Әти сука сөргән җир............................................135
Дулкыннар дулый................................................136
Әрне-хурны белмисең............................................137
Сүз ишеттем....................................................138

Вакыт җитми.......................................139
Кич утырган кызлар.......................................140
Киртәләр бар юлларымда.......................................141
Көтеп яшим.......................................142
Кайгы килсә.......................................143
Түрәләр төрле була.......................................144
Сер түгел.......................................145
Йолдызлар җиле.......................................146
Хыяллар белән яшим.......................................147
Кулымда тормыштезгене.......................................148
Хәлең мөшкел.......................................149
Дөнья яктысы.......................................150
Күкри яшьлек җырыбыз.......................................151
Гомерләр уза.......................................152
Дусларым күп.......................................153
Мине аңларсың бәлки.......................................154
Агын да бар, күгең дә.......................................155
Мин ышанам көчемә.......................................156
Вакыт сагында тора.......................................157
Поездлар узган чакта.......................................158
Мәҗлес.......................................159
Көндә казлар куасың.......................................160
Мине табарсың.......................................161
Дөнья артыннан кумыйм.......................................162
Елмаюың калсын.......................................163
Таллар булып бөгеләм.......................................164
Нигә газап чигәргә?.......................................165
Бар кеше да шагыйрь.......................................166
Теләкләргә ирешмәдек.......................................167
Карашыңны сагынам.......................................168
Сөюдә сыналасың.......................................169
Гомер сукмагы (поэма).......................................170

Литературно-художественное издание

*Суфияров Фарит Суфиярович*

"Звездные ветра"

(на татарском языке)

Подписано в печать 16.2.2006. Формат 70x90/1/16
Гарнитура ATimes.
Офсет. Тираж 1000 экз. Заказ № 60261
Издательство «Слово», г. Уфа, проспект Октября, 16.
Тел. 25-91-86, 24-89-38
E.mail: ipslovo@ufanet.ru

Отпечатано с предоставленных файлов
на Государственном унитарном предприятии Республики
Башкортостан
"Издательство "Белая река".
450078, Уфа, ул. Кирова, 109